ОБЩЕСТВЕННАЯ ПАЛАТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫ

# 2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында

# ДОКЛАД

ОБЩЕСТВЕННАЯ ПАЛАТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫ

# 2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында

# ДОКЛАД

Казань
2026

**2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында доклад. Казан: Казан инновацион университетының «Познание» нәшрияты, 2026. – 60 б.**

**Докладны әзерләү буенча эшче төркем**: *А.М. Терентьев (эшче төркемнең җитәкчесе), О.Д. Агапов, И.А. Александровская, Ә.Ф. Вәлиева, А.Ф. Гыймадетдинов, Т.Р. Кадыйров, Т.Г. Какохо, А.Р. Мөхәммәтҗанов, М.В. Нефедова, Д.Ф. Нургалиев, С.В. Салмина, А.Р. Сафиуллин, А.В. Тимирясова, Т.Т. Федорова, Е.В. Храмова, И.И. Яркова*.

Доклад Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Советының 2026 елның 6 апрелендәге карары белән расланды.

Әлеге докладны әзерләгәндә 2025 елда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы уздырган утырышлар, түгәрәк өстәлләр, кайнар линияләр һәм гавами тыңлаулар материаллары, Иҗтимагый палатаның даими профильле комиссияләре һәм эшче төркемнәре аналитикасы, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы йомгаклау докладының төп нигезләмәләре файдаланылды. Моннан тыш, үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре, массакүләм мәгълүмат чараларындагы публикацияләр, дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары, иҗтимагый советлар, коммерциягә карамаган оешмалар мәгълүматы, гражданнар мөрәҗәгатьләре файдаланылды.

# Эчтәлек

Кереш........................................................................................... 4

1. Граждан җәмгыятенең абруйлы институты:
Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына – 20 ел ... 7

2. Хакимият һәм граждан җәмгыяте: диалог һәм
партнерлык.................................................................................. 10

3. Дәүләт ярдәме чаралары .................................................. 29

4. Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы ................................ 41

5. Ватанпәрвәрлек, әхлаклылык, гаделлек:
граждан җәмгыяте кыйммәтләре .......................................... 50

6. Сынаулар һәм үсеш мөмкинлекләре ................................ 57

Йомгаклау.................................................................................... 60

# Кереш

Граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында доклад, ул, иң элек, граждан җәмгыятенең төрле өлешләрендә һәм институтларында барган процессларны, аларның хакимият органнары белән хезмәттәшлеге тәҗрибәләрен анализлау, бүгенге көн бурычларын исәпкә алып, алга таба үсеш юлларын билгеләү.

Граждан җәмгыяте җитлегүенең мөһим күрсәткече булып гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең, тулаем алганда, коммерциягә карамаган секторның республиканың социаль-икътисадый үсешенә, кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга ярдәм итүче позитив эшчәнлеккә җәлеп ителүе тора.

Хакимият органнарының, бизнес-җәмәгатьчелекнең һәм җәмгыятьнең тырышлыгын берләштерү ярдәмендә Татарстан төп икътисадый күрсәткечләр буенча тотрыклы динамика күрсәтә, Россиянең терәк регионы буларак, аның куәтен ныгытуга саллы өлеш кертә. Масштаблы проектлар һәм программалар, республиканың инновацион инфраструктурасы һәм инвестицияләрне җәлеп итүчәнлеге шуңа юнәлдерелгән.

Болар барысы да яшәүнең югары стандартларын һәм җәмгыять үсешенең алшартларын билгели. Татарстан – коммерциягә карамаган оешмаларның саны һәм аларның проект активлыгы буенча да, граждан җәмгыяте институтларының нәтиҗәлелеге, хакимият органнары белән хезмәттәшлекнең эшләнгән тәҗрибәләре буенча да илнең алдынгы төбәкләрнең берсе.

Бай тарихи-мәдәни мираска, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләргә таянган мондый эшчәнлек граждан татулыгы, милләтара һәм динара тынычлык һәм үзара аңлашу, дәүләт һәм җәмгыять арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр мохитен булдыруга хезмәт итә.

Граждан җәмгыятен һәм аның институтларын уңышлы үстерүнең төп факторы – гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре гаранты буларак Президентның, Татарстан Республикасы Рәисенең ачык белдерелгән сәяси ихтыяры. Җәмәгать активистлары тырышлыгына тапкырланган дәүләт ярдәме чаралары системасы җәмгыять үсешенә динамика һәм конструктивлык бирә.

Узган елның төп иҗтимагый-сәяси вакыйгасы булып республика Рәисен һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлаулар булды. Нәкъ менә сайлаулар һәрвакыт гражданнарның һәм, тулаем алганда, җәмгыятьнең хакимияткә һәм ул гамәлгә ашыра торган юнәлешкә карата ышанычының үлчәве булып тора. Бүгенге көндә артып торучы тышкы сынаулар һәм дустанә булмаган илләр тарафыннан Россиягә янаулар шартларында бу бигрәк тә мөһим.

2024 елда ил Президентын сайлау нәтиҗәләре россиялеләр өчен горурлык, берләшү һәм Ватан мәнфәгатьләрен яклауда бердәм булу чыганагы булган кебек, Татарстан Рәисен сайлау да татарстанлыларның активлыгын, берләшүен, республиканы ныгыту һәм үстерү юлын хуплавын күрсәтте.

Тавыш бирү өчен булдырылган шартлар, җәмәгатьчелекнең сайлауларны күзәтүдә актив катнашуы, аларның биштән берен Иҗтимагый палата күзәтүчеләре тәшкил итте, тавыш бирү процессының ачыклыгын һәм аның нәтиҗәләренә ышанычны тәэмин итүгә, провокацияләрне булдырмауга һәм сайлаучыларның мөрәҗәгатьләрен тиз арада карауга ярдәм итте.

Узган ел – Ватанны саклаучылар елы – татарстанлыларның бердәмлегенең югары дәрәҗәсен, аларның бөек рухи-әхлакый кыйммәтләргә тугрылыгын күрсәтте. Хакимият органнарының, иҗтимагый оешмаларның, коммерциягә карамаган оешмаларның, гражданнарның Бөек Ватан сугышының героик вакыйгалары, фронттагы һәм тылдагы сугыш каһарманнары, ата-бабалар традицияләрен дәвам итүче махсус хәрби операциядә катнашучылар турында истәлекне саклау буенча масштаблы инициативалар гамәлгә ашырылды. Бу традицияләрнең дәвамчанлыгын, Ватан тарихына һәм Җиңүчеләр буынына хөрмәт күрсәтүне раслаучы ачык дәлил булды!

Иҗтимагый палата, коммерциягә карамаган оешмалар һәм гражданнар махсус хәрби операция зонасындагы сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә, шефлыктагы Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә һәрьяклап ярдәм итүдә, гуманитар ярдәмне җыюда һәм җибәрүдә актив катнашты.

Ихтыярыйлык хәрәкәте актив үсте. Иҗтимагый әһәмиятле проектларның киң спектры гамәлгә ашырылды. Ватанпәрвәрлеккә һәм традицион кыйммәтләргә таяну җәмгыятьне игелеклерәк, гаделрәк итте һәм итә, граждан бердәмлеген формалаштыра. Коммерциягә карамаган секторны ныгыту граждан инициативасын стратегик социаль ресурска әйләндерде.

Республиканың югары үсеш дәрәҗәсе, аның Россия тышкы сәясәте концепциясе кысаларында күп кенә төбәкләр һәм илләр белән хезмәттәшлеге халык, җәмгыять дипломатиясен урнаштыруга ярдәм итә. Моны «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» һәм «Kazan Digital Week» халыкара форумнары

кысаларында җәмгыять үсеше һәм коммерциягә карамаган секторны үстерү буенча актуаль мәсьәләләргә багышланган түгәрәк өстәлләр күрсәтте.

Гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән нәтиҗәле кире элемтә каналлары ярдәмендә хакимият органнары һәм Иҗтимагый палата җәмгыять үсеше мәнфәгатьләренә җавап бирүче актуаль көн тәртибен булдырырга омтылды. Шул ук вакытта, республиканың югары дәрәҗәдәге куәте җәмгыять тарафыннан бурычлар куелуга, билгеле бер тәнкыйтькә, бәхәсләргә, битараф булмаган гражданнарның тәкъдимнәренә китерә. Мондый активлык, конструктив корылган диалог уңышлы киләчәк күренешен формалаштыруга ярдәм итә, социаль тотрыклылык нигезен ныгыта.

# 1. Граждан җәмгыятенең абруйлы институты: Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына – 20 ел

Илнең иҗтимагый-сәяси төзелеше җимерелгәннән һәм массаларның социаль энергиясе азат ителгәннән соң, дәүләтнең алга таба үсешен эзләү һәм бу эштә җәмгыятьнең катнашуы буенча актив процесс барды. Реформаларның каршылыклы булуын исәпкә алып, төрле юнәлешләрдәге һәм карашлардагы йөзләгән иҗтимагый берләшмәләр барлыкка килде. Республикада дүрт меңнән артык оешма эшләде.

Тиешле дәүләт җайга салуының һәм активистларның эш тәҗрибәсенең булмавы, шулай ук килеп чыккан иректән тулысынча файдалану омтылышы, шул исәптән түземсезлек һәм радикаль идеяләр белән аерылып торган формированиеләрне дә барлыкка китерде. Иҗтимагый процессларны тотрыклыландыру, дәүләтнең һәм җәмгыятьнең хезмәттәшлегенә конструктив характер бирү кирәк иде.

Федераль дәрәҗәдә һәм республикада хакимият органнары һәм җәмгыять арасында диалог урнаштыру омтылышлары ясалды. Иҗтимагый һәм координацион советлар төзелде, түгәрәк өстәлләр үткәрелде һәм платформалар төзелде. ТР Президенты аппаратында бу мәсьәләләрне җәмәгатьчелек белән багланышлар һәм милләтара мөнәсәбәтләр буенча төзелгән бүлек координацияләде.

Ул вакытта республикада Бөтендөнья татар конгрессы (ВКТ), Милли-мәдәни оешмалар ассоциациясе (АНКО), Яшьләр оешмалары советы (СМО), Һөнәр берлекләре федерациясе, дини формированиеләр һәм күпчелек Татарстан оешмаларын берләштергән башка формированиеләр кебек күп кенә «чатырлы» структуралар үзләрен яхшы күрсәтте.

Бердәм иҗтимагый үзәк төзү кирәклеге идеясе Россия Президенты тарафыннан 2004 елның сентябрендә әйтелде. Сүз җәмәгать күзәтчелеге системасында үзәк урын алачак һәм җәмгыять һәм хакимият арасында диалог өчен төп мәйданчык булачак махсус институт турында барды.

2005 елның уртасында ук Иҗтимагый палата турында федераль закон үз көченә керде. Шундый кыска вакыт аралыгында яңа дәүләти-иҗтимагый модельне эшләтеп җибәрү ул чордагы вазгыятьнең кискенлеге белән аңлатыла.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасында да шундый ук закон проекты буенча эш алып барылды һәм әлеге закон 2005 елның көзендә үз көченә керде.

Россия Иҗтимагый палатасының беренче утырышы ил Президенты катнашында 2006 елның 22 гыйнварында узды, ә инде 27 гыйнварда Татарстан Иҗтимагый палатасының беренче утырышы үтте.



Палатаның беренче составына мөрәҗәгать итеп, республика Президенты М.Ш. Шәймиев: «Иҗтимагый палата <...> җәмгыятьнең үзеннән чыккан социаль әһәмиятле башлангычларның «катализаторы» булырга тиеш. Иҗтимагый палата төзүнең мәгънәсе өлешчә нәкъ менә шунда – барлык иҗтимагый берләшмәләрнең көчләрен берләштерү. Бер юнәлештә эшләү, уртак тел табу, көн кадагындагы мәсьәләләргә үз мөнәсәбәтеңне белдерү, үз фикереңне хакимияткә, закон чыгару органнарына җиткерү һәм шуның белән бергә Иҗтимагый палатага йөкләнгән кешелеклелек миссиясен үтәү – җәмгыятькә хезмәт итү, бөтен җәмгыять исеменнән сөйләү һәм ишетелгән булу. <...> сез – эшне башлап җибәрәчәк, традицияләргә нигез салачак, Иҗтимагый палатаның алдагы составларына юл күрсәтәчәк состав», дип билгеләп үтте.

Иҗтимагый палата төзелүгә һәм аның эшчәнлегенең төп юнәлешләренә палатаның беренче рәисе И.К. Хәйруллин һәм ул чорның иҗтимагый фикер алдынгылары булган палата әгъзаларының күбесе зур йогынты ясады.



Гражданнарны кабул итү, актуаль мәсьәләләр буенча гавами тыңлаулар, закон проектларына бәяләмәләр әзерләү, министрлар хисаплары, түгәрәк өстәлләр һәм бәхәсләр, резонанслы вакыйгалар буенча күчмә чаралар – болар барысы да җәмәгать активистларының тырыш эшчәнлеге предметы булды.

Иҗтимагый палата, хакимият органнарының тулы хокуклы партнеры булып, граждан җәмгыяте мәнфәгатьләрен белдерүче әйдәүче ролен уйнады. Россия Иҗтимагый палатасы белән хезмәттәшлек үсте. Республиканың эшчәнлеге һәм тәҗрибәсе илдә иң яхшыларның берсе дип танылды.

Алга таба законнар камилләштерелде, хакимият органнары белән килешүләрне гамәлгә ашыру, гавами өстенлекләрне һәм максатларны формалаштыру, җәмәгать күзәтчелеге комиссияләрен формалаштыру, министрлыкларда һәм муниципаль дәрәҗәдә иҗтимагый советлар төзү тәҗрибәсе эшләнде. Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга аеруча ярдәм күрсәтелде, грант системасы формалаштырылды.

Кешеләрнең соратуларын, кызыксынуларын һәм фикерләрен, аларның проблемаларны һәм аларның чишелешләрен күзаллауларын исәпкә алып, заман тенденцияләрен чагылдыручы башка яңа инструментлар һәм институтлар барлыкка килде.

Ләкин һәрвакыт балансны табу, бер яктан гражданның, җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен, икенче яктан дәүләт мәнфәгатьләрен исәпкә алу бурычы үзгәрешсез калды. Бу – Иҗтимагый палатаның даими бурычларының берсе. Бигрәк тә бу пандемия вакытында һәм МХО барышында күренде, бу вакытта, күпчелек позицияләр бер булганда, иҗтимагый әһәмияткә ия булган позициядән чыгып вакыйгаларның үсешенә тәнкыйди карашны саклап калу мөһим булды.

Бүген иҗтимагый палата, граждан җәмгыяте – уртак киләчәк турында кайгырту эшенә җәлеп ителгән битараф булмаган һәм актив гражданнар. Бу – республиканы үстерүдә иң мөһим ресурс.

Ике дистә ел эчендә дәүләт һәм җәмгыять арасындагы диалог тотрыклы рәвеш алды, граждан җәмгыятенең моделе формалашты. Иҗтимагый палата бәйсез фикер алышу мәйданчыгын да, гражданнар һәм хакимият органнары мәнфәгатьләрен килештерү механизмын да, җәмгыять ышанычын ныгытучы чишелешләр эзләү инструментын да чагылдыра.

# 2. Хакимият һәм граждан җәмгыяте: диалог һәм партнерлык

## Граждан җәмгыяте саннарда

Татарстанның граждан җәмгыяте оештыру-хокукый рәвеше, юнәлеше һәм эшчәнлек төрләре буенча төрле булган иҗтимагый оешмаларның, коммерциягә карамаган оешмаларның һәм берләшмәләрнең иң киң спектрыннан гыйбарәт.

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча, агымдагы елның башына 6199 коммерциягә карамаган оешма теркәлгән, шулардан:

– иҗтимагый берләшмәләр – 1599;
– сәяси партияләрнең региональ бүлекләре – 16;
– дини оешмалар – 2173;
– башка коммерциягә карамаган оешмалар – 2411.

**Татарстан Республикасында коммерциягә карамаган оешмалар саны**



Гомумән алганда, бу Идел буе федераль округында сан буенча икенче күрсәткеч булып тора.

2025 елда РФ Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 2024 ел өчен үз эшчәнлекләре турында хисапларны 2699 коммерциягә карамаган оешма тапшырды.

Узган елда 293 яңа оешма теркәлде һәм 318 оешма үз эшчәнлеген туктатты (69 коммерциягә карамаган оешма ябылу турында карар кабул итте, 64 – салым органы карары, 185 суд карары белән бетерелде).

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына 1 238 коммерциягә карамаган оешма керә.

Коммерциягә карамаган оешмаларның 40% диярлек Казанда теркәлгән.

Иҗтимагый, коммерциягә карамаган оешмалар җәмгыять структурасында аерым урын алып тора. Алар, кагыйдә буларак, дәүләт һәм бизнес тарафыннан хәл ителмәгән социаль проблемаларны хәл итүче көчләр булып тора. Алар беренче булып яңа сынауларга һәм проблемаларга җавап бирә, җәмгыять ихтыяҗларының үзенчәлекле индикаторы булып, җәмгыять ышанычының югары дәрәҗәсенә ия.

Иң массакүләм һәм йогынтылы иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр арасында Бөтендөнья татар конгрессын (513 оешманы берләштерә), «Татарстан халыклары ассамблеясы» региональ иҗтимагый оешмасын (270 милли-мәдәни берләшмә һәм оешма), «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасын (44 оешма), Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясен (якынча 5 мең беренчел оешма), Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтен (1625 оешма), Рус православие чиркәвенең Татарстан митрополиясен (466 приход), Татарстан Республикасы Яшьләр оешмалары Советын (24 оешма), Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) региональ иҗтимагый оешмасын (якынча 2 мең беренчел оешма), «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» региональ яшьләр иҗтимагый оешмасын (200дән артык студент берләшмәсе), «Созвездие-Йолдызлык» региональ яшьләр иҗтимагый оешмасын (15 мең катнашучы), иҗади берлекләрне, төрле социаль юнәлешле оешмаларны һәм башка оешмаларны билгеләп үтәргә кирәк.

Республиканың граждан җәмгыятен үстерүдә 638 массакүләм мәгълүмат чарасы аерым роль уйный, алар җәмгыятьнең дәүләт белән хезмәттәшлегендә ышанычлы канал булып тора. Коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген, иҗтимагый башлангычларны һәм хәйрия проектларын системалы рәвештә яктырту коммерциягә карамаган секторның уңай йөзен формалаштыруга һәм социаль әһәмиятле темаларга игътибарны җәлеп итүгә ярдәм итә.

Җәмгыять фикеренә сизелерлек йогынтыны челтәр бергәлекләре ясый. Мәсәлән, «Типичный Чистополь – На Бебеля» (Чистай шәһәрендә яшәүчеләрнең рәсми булмаган бергәлеге, 15 мең язылучы, айга 3 миллионнан артык карау),

«Түбән Кама яңалыклары» (49 800 язылучы, айга 9 миллионнан артык карау), «Энтер медиа» (шәһәр бергәлекләре һәм активлыклары турында челтәрле медиа, айга 2 миллионнан артык карау). Алар инде шактый танылган иҗтимагый күренешкә әйләнде. Төрле социаль һәм территориаль катламнардан торып, алар диалог мәйданчыгы буларак та, соратуларга оператив җавап бирү, ялган мәгълүматны һәм фейкларны таратуны булдырмау, гражданнарны актуаль мәсьәләләр турында фикер алышуга җәлеп итү мөмкинлеген бирүче инструмент та булып тора.

## Кире элемтә каналлары системасы

Татарстанда формалашкан җәмгыятькә җәлеп ителү һәм кире элемтә тәҗрибәсе үз эченә каналларның һәм платформаларның киң даирәсен ала торган күпбаскычлы һәм үзара бәйләнешле системаны тәшкил итә. Бу, җәмәгать кабул итү бүлмәләрен һәм кайнар линияләрне дә кертеп, гражданнарны кабул итүнең һәм аларның мөрәҗәгатьләрен кабул итүнең традицион рәвешләре. Бу – Дәүләт хезмәтләре порталы, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Инцидент-менеджмент» җавап бирү системасы кебек цифрлы платформалар. Моңа министрлыкларның максатларын һәм бурычларын гавами формалаштыру механизмнары, «Безнең ишегалды» һәм җәмәгать урыннарын булдыру программаларын инициативалы бюджетлау элементлары, шулай ук аларда активлыклар оештыру да юнәлдерелгән.

Җәмәгать активистлары белән даими очрашулар, массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар тарата торган мәгълүмат һәм Иҗтимагый палатаның доклады һәм йомгаклау хисабы, үткәрелә торган социологик тикшеренүләр яхшы кире элемтә бирә.

Боларның барысы да республикада «аңлаучы дәүләт» тотрыклы моделе формалашкан дип әйтергә мөмкинлек бирә, анда, иң мөһим карарлар кабул иткәндә, граждан тавышын исәпкә алырга тырышалар, ә хакимият һәм җәмгыять арасындагы диалог конструктив була.

Җәмгыять белән кире элемтәнең иң мөһим традицион каналы булып **гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү** тора, бу конкрет проблемаларны хәл итәргә генә түгел, ә дәүләт структуралары һәм муниципаль структуралар эшендә системалы өзеклекләрне ачыкларга да мөмкинлек бирә. Гражданнарны кабул итү барлык хакимият органнары һәм тиешле закон белән билгеләнгән башка субъектлар тарафыннан алып барыла.

2025 елда Иҗтимагый палата, аның структуралары һәм экспертлары тарафыннан гражданнарның 1 471 мөрәҗәгате каралды. Социаль өлкә, торак-коммуналь хуҗалык, хокук мәсьәләләре һәм шәһәр мохите инфраструктурасы аларның күпчелеген тәшкил итә. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүдә басым, аерым җавап бирүдән конфликтлы хәлләрне булдырмауга күчеп, мөһим проблемалар буенча системалы чишелешләрне эшләү кирәклегенә ясалды.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе тарафыннан 116 кеше кабул ителде. Күпчелекне коммерциягә карамаган сектор проектларын гамәлгә ашыруга, МХОдә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүгә, кадрлар әзерләүгә, әйләнә-тирә мохитне саклауга, торак-коммуналь хуҗалыкка, сайлауларда җәмәгать күзәтүен оештыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләр тәшкил итә.

Иҗтимагый палата белән килешү буенча Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы тарафыннан 47 кабул итү үткәрелде һәм юридик мәсьәләләр буенча 202 консультация күрсәтелде. Мәсьәләләр нигездә җир-мөлкәт мөнәсәбәтләренә, суд карарларына шикаять бирүгә, башкару производствосы буенча түләтүләргә һәм башкаларга кагыла.

Иҗтимагый палата эксперты Г.Г. Балафендиева тарафыннан миграция мәсьәләләре буенча 578 консультация күрсәтелде. Эксперт Ф.С. Хөсәенов тарафыннан халыкны кредитлау, финанс бөлгенлеге, финанс мошенниклыгы һәм уенга бәйлелек буенча 203 консультация үткәрелде. Ул шул ук темалар буенча 2350 кеше өчен лекцияләр үткәрде.

**«Кайнар линияләр»** гражданнарда көндәлек актуаль мәсьәләләр буенча күпсанлы сораулар барлыкка килгәндә тыныч булмаган вазгыятьтә җәмгыятьтәге киеренкелекне киметүгә **ярдәм итә**.

Июньдә Иҗтимагый палата тарафыннан балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләләре буенча кире элемтә каналы оештырылды. Сораулар путевкалар алу мөмкинлегенә, балаларның, бигрәк тә медицина күрсәтмәләре булган балаларның, туклануына, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялына һәм башкаларга кагылды. «Җәй» республика үзәге һәм профильле ведомстволар белән берлектә 30дан артык мәсьәлә хәл ителде.



Инвалидлар ункөнлеге кысаларында Иҗтимагый палатада тар өлкә белгечләре белән берлектә реабилитацияләү, электрон сертификатлар, дару чаралары алу, реабилитацияләүнең техник чаралары белән тәэмин итү, инвалидларның белем алуы, инвалидлык төркемен билгеләү һәм башка мәсьәләләр буенча 57 граждан кабул ителде.

Шулай ук менталь тайпылышлары булган балаларга һөнәри юнәлеш бирү, урта һөнәри белем бирү һәм аларны алга таба эшкә урнаштыру мөмкинлеге, мәктәп туклануын оештыру мәсьәләләре һәм башка мәсьәләләр буенча кайнар линияләр үткәрелде.

Җәмгыять кәефенең аерым барометры, тәнкыйди бәяләмәләрне һәм тәкъдимнәрне белдерү каналы булып Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил координацияләвендә гамәлгә ашырыла торган цифрлы инструментлар: «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы һәм «Инцидент-менеджмент» системасы хезмәт итә.

2025 елда **«Халык контроле» системасында** 89 186 хәбәрнамә (гражданнарның адреслы мөрәҗәгатьләре) бастырылды. Аларның 68 883е яисә 77% хәл ителде. 15% буенча эшләр планлаштырылды, 7%на дәлилле кире кагу бирелде, 1% эштә булды.

Иң күп хәбәрнамәләр «Төзекләндерү һәм инфраструктура» (39 185), «Юллар» (27 748), «Торак-коммуналь хуҗалык» (10 142), «Каты коммуналь калдыклар» (3400), «Транспорт» (2 862), «Сәламәтлек саклау» (1725), «Экология» (1230), «Сәүдә» (1 116) юнәлешләре буенча килде.

Шул ук вакытта эшләр планлаштырылган хәбәрнамәләрнең 15% республика халкын алга таба җәмгыять контролен – мәсьәләне чишүне мониторинглауга җәлеп итүне күрсәтә.

**«Инцидент-менеджмент» системасы** гражданнарның социаль челтәрләрдәге хәбәрләрен ачыкларга һәм эшкәртергә мөмкинлек бирә. Хакимият органнары республика халкы үзләре яшәгән шәһәрләр һәм авыллар проблемалары хакында актив фикер алышкан цифрлы киңлекләрдә халыктан кире элемтә ала.

2025 елда система тарафыннан 88 меңгә якын хәбәр эшкәртелгән. Төп күрсәткечләр булып җавап бирү оперативлыгы һәм «хәбәрләрнең хәл ителүе» тора.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөрәҗәгатьләрен эшкәртүгә аеруча игътибар бирелде, ярдәм чаралары һәм аларны алу ысуллары турында мәгълүматны берләштерүче «МХОдә катнашучыларны кайгырту» цифрлы платформасы булдырылды. Ресурсны 210 меңнән артык кеше карады.

Хакимият органнарының эшчәнлеге һәм гамәлгә ашырыла торган проектлар турында төрле мәгълүмат алу өчен киң мөмкинлекләрне

**Ачык Татарстан** порталы бирә. Актив яшәүчеләр өчен проектларны **«Дәүләт хезмәтләре» тәкъдим итә**. Фикер алышуга чыгарылган актуаль мәсьәлә буенча фикер белдерү мөмкинлеге каралган. Шунда ук сораштыру үтәргә һәм ишегалды территорияләрен комплекслы төзекләндерүгә юнәлдерелгән **«Безнең ишегалды»** программасын гамәлгә ашыруда шәхси катнашырга (уртак проектлау), шулай ук «Күрше» бәйгесендә катнашырга һәм үзеңнең ишегалдында яисә җәмәгать урынында активлыклар оештыруга 1 млн сум отарга мөмкин. Мондый катнашу күршеләрнең тату яшәвенә һәм төзекләндерелгән ишегалларында чаралар (фестивальләр, бәйрәмнәр, мастер-класслар һ.б.) оештыру аша вакытны эчтәлекле үткәрүгә ярдәм итә.

«Безнең ишегалды» программасы буенча тавыш бирүдә 416 357 кеше катнашты, шул исәптән 130 057 казанлы, 56 113 чаллылы һәм 28 905 түбән камалы. Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле һәм Мөслим районнары халкы иң зур активлык күрсәтте. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча республиканың 45 районының һәрберсендә агымдагы елда төзекләндерeләчәк үз җиңүче объекты билгеләнде.

**Җәмәгать контроле** Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан актив кулланыла торган кире элемтә һәм вазгыятькә йогынты ясау механизмнарының берсе булып тора. Ул җәмәгать тыңлауларыннан һәм мониторинглардан алып тикшерү чараларына һәм актуаль мәсьәләләр буенча докладлар әзерләүгә кадәр күп төрле рәвешләрдә булырга мөмкин.

2025 елда балалар ялы һәм экологик иминлек өлкәсендә урыннарга чыгып тикшерүләр башкарылды. Тикшерүләр түбәндәге лагерьларда һәм үзәкләрдә узды: «Мирас-Наследие», «Заречье», «Идел» яшьләр үзәге, «Дуслык» сәламәтләндерү, белем бирү комплексы, «ҖӘЙ» балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, аларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча республика үзәге, «Игелекле» лагере, «Камский Артек», «Акчарлак» лагерьлары.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча санап үтелгән лагерьларда, тулаем алганда, уңайлы шартлар тудырылган, эчтәлекле программалар гамәлгә ашырыла дип билгеләнде.

Берничә ел дәвамында ләм кырларын рекультивацияләү барышына җәмәгать экология контроле алып барыла. Куйбышев сусаклагычына ләм утырмалары төшү мөмкинлеген ачыклау максатында ләм кырларының тышкы периметры буйлап су сыйфаты тикшерелде. Шулай ук Серов урамындагы күлне чистарту җәмәгать контролендә алып барылды, активистлар инспекторлар белән берлектә урыннарга чыгып башка тикшерүләрдә һәм табигатьне саклау законнарын бозуны теркәүдә катнашты.

Билгеләп үтелгән кире элемтә каналлары һәм алар буенча алынган мәгълүматлардан тыш, идарәчел карарлар кабул ителгәндә көндәлек актуаль мәсьәләләр буенча фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан үткәрелә торган **дистәләгән сан һәм сыйфат тикшеренүләре кулланыла**.

## Киң форматлы диалог

Һичшиксез, кире элемтә каналлары, фикерләр һәм тәкъдимнәр җыелмасы алга таба конструктив диалог төзү өчен хәлиткеч әһәмияткә ия. Нәкъ менә аңарда уңышлы киләчәк күренеше формалаша. Шуңа күрә үзара мөнәсәбәтләр форматы, бәхәстә һәм тәнкыйтьтә яңа, кызыксынган якларны канәгатьләндерә торган проблемалар чишелешен күрү осталыгы шулкадәр мөһим. Диалог булмау һәм җәмәгать фикерен исәпкә алмау – котылгысыз рәвештә протест активлыгына китерү юлы.

Республикада диалогның иң төрле рәвешләре һәм, дәүләт һәм җәмгыять позицияләрен исәпкә алып, хәл итү юлларын эшләү тәҗрибәсе формалашты.

**Түгәрәк өстәлләр һәм бәхәсләр**, проблемалы мәсьәләләр буенча **фәнни-гамәли конференцияләр** һәм тыңлаулар киң кулланыла.




2025 елда «ачык хәйриячелек», дини оешмаларның халыкара хезмәттәшлек потенциалын үстерү, дару чаралары һәм медицина эшләнмәләре белән эш итү өлкәсендә җайга салу, Татарстанда инклюзив практикаларны үстерү, социаль үзгәрешләр өчен ясалма интеллектны куллану, ТРда «хезмәт белән өйрәтү»нең тәҗрибәләре һәм үсеш перспективалары, авыр тормыш хәлендәге кешеләргә планлы медицина ярдәме күрсәтү һәм башка мәсьәләләр буенча түгәрәк өстәлләр үткәрелде.

Фәнни-гамәли конференцияләрдә түбәндәге темалар каралды: «Тел, җәмгыять һәм мәгълүмат технологияләре», «Грантмейкинг: булдырабыз, кертәбез, үстерәбез», коррупциягә каршы көрәш һәм башкалар.

**Тармак Иҗтимагый советлары утырышларында министрларның катнашуы**, максатчан программаларны гамәлгә ашыру, үсеш өстенлекләрен эшләү хакында уртак фикер алышу диалогның мөһим элементы булып тора.

Иҗтимагый палата мәйданчыгында **социаль блок министрлыкларының** гавами формалаштырылган максатларны һәм бурычларны үтәве турында хисабы мөһим һәм көтелгән чара булды. Мондый фикер алышулар нәтиҗәләре алга таба министрлыкларның эш планнарын формалаштырганда исәпкә алына.

**Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар форумнарын уздыру** тәҗрибәсе хакимият һәм җәмгыять диалогының шактый нәтиҗәле рәвешенә әверелде. Аларның максаты – актуаль булган социаль проблемаларны хәл итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларның хакимият һәм бизнес органнары белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, коммерциягә карамаган оешмаларның, иҗтимагый оешмаларның, активист гражданнарның иң яхшы тәҗрибәләрен һәм коммерциягә карамаган секторның республиканың социаль-икътисадый үсешенә керткән өлешен арттыру юлларын тәкъдим итү.

Инициативалы гражданнарны, коммерциягә карамаган оешмаларны һәм эксперт бергәлеген, бизнесны һәм хакимият органнарын киң җәлеп итеп секцияләрдә фикер алышулар һәм пленар утырышлар үткәрү аша форумнар граждан җәмгыяте институтларының үзара эшчәнлеген камилләштерү һәм аларны үстерү өчен нәтиҗәле инструмент булып тора. Уздырылган биш форум (2011, 2013, 2015, 2017, 2022 елларда) республика өчен хәлиткеч роль уйнады. Бу социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына конкурс үткәрү турында, грантлар хакында, коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктырту турында, граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен премияләр хакында, дәүләтнеке булмаган оешмаларга, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчалары турында карарларга һәм башкаларга кагыла.

## Кызыксынган партнерлык

Дәүләтнең һәм җәмгыятьнең кызыксынган партнерлык мөнәсәбәтләренең, коммерциягә карамаган секторны дәүләт бурычларын хәл итүгә һәм иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга җәлеп итү рәвешләренең тотрыклы институтлары һәм механизмнары бар.

**Иҗтимагый, коммерциягә карамаган оешмаларның стратегик характердагы дәүләт документларын һәм максатчан программаларны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашуы** гадәти тәҗрибәгә әверелде һәм җәмәгатьчелекнең барлык этапларда да актив катнашуын күздә тота.

Бу программа чараларының аерым нигезләмәләре һәм пунктлары буенча инициатива белән чыгуга, документны эшләгәндә аларны яклауга, алга таба инициаторларны аңа башкарышучылар сыйфатында кертүгә, әлеге нигезләмәләрне гамәлгә ашыру өчен үз өлешендә хисап тотуга кагыла. Шул рәвешле уртак эшчәнлекнең иҗтимагый-дәүләти характеры формалаша. Мондый партнерлыкның ачык характеры дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру буенча программалар комплексын гамәлгә ашырганда аеруча ачык күренә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында Россиядә һәм аннан читтә татар мәдәниятен популярлаштыру проектларын гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмаларны финанслау механизмын (грантлар, субсидияләр) беркетү мөһим яңалык булды.

Кызыксынучанлыкка мисал итеп Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясының «Халыклар дуслыгы – Татарстан байлыгы» республика белем бирү форумнарын һәм «Милли – актуаль» этнопроектларның Яшьләр форумын уздыруны билгеләп үтәргә була. Республиканың Рус милли-мәдәни берләшмәсе «Татарстан музейларында рус коллекцияләре» дигән биш томлык тарихи-этнографик каталог бастырып чыгарды, Максим Горькийның 155 еллыгына багышланган чаралар циклын үткәрде, бөтенроссия премиясе лауреаты дипломы белән билгеләнгән «Пушкин һәм Казан» масштаблы проектын тормышка ашырды.

Моннан тыш, кайбер коммерциягә карамаган оешмалар дүрт милли проектның («Яшьләр һәм балалар», «Гаилә», «Сәламәтлек саклау», «Кадрлар», «Экологик иминлек») аерым чараларын гамәлгә ашыруда катнаша. Һичшиксез, мондый эшчәнлек кызыксынган партнерлыкның төп куәте булып тора.

Социаль әһәмиятле бурычларны гамәлгә ашыруда хакимият һәм җәмгыятьнең уртак эшчәнлегенең зарурлыгы **Иҗтимагый палата һәм Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары арасында хезмәттәшлек турында 15 килешүнең** эчтәлеген алдан билгеләде.

2006 елда ук беренчеләрдән булып килешүләрне «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы имзалады.

Иҗтимагый палата һәм коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре коллегияләр һәм ведомствоара эш төркемнәре утырышларында актив катнаша. Үз чиратында министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре Иҗтимагый палатаның, коммерциягә карамаган секторның күп кенә чараларында катнаша. Мондый хезмәттәшлек көндәлек актуаль мәсьәләләрне хәл итүдә үзара аңлашуга һәм көч туплауга ярдәм итә.

Татарстан халыклары Ассамблеясына керүче оешмалар һәм дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен әйдәп баручы министрлыкларның уңышлы гамәлгә ашырыла торган хезмәттәшлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Булдырылган модель Ассамблея советын аңа министрлыкларның җитәкче составы вәкилләре һәм милли-мәдәни автономияләр лидерлары керүгә нигезләнеп формалаштыруны күздә тота, бу исә кабул ителә торган карарлар турында һәрьяклап уйларга, аларны гамәлгә ашыруда көчләрне берләштерергә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Хөкүмәтенең эш регламентлары **иҗтимагый әһәмиятле закон проектларын һәм норматив-хокукый актларны әзерләгәндә Иҗтимагый палатаның эксперт эшчәнлегендә катнашуын** күздә тота.

2025 елда Татарстан Республикасының 121 закон проекты һәм Россия Федерациясенең 11 федераль закон проекты каралды һәм аларга бәяләмәләр әзерләнде. Иҗтимагый палата әгъзасы Д. Нургалиев Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән берлектә норматив-хокукый актларга 18 тәкъдим кертте. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларында һәм «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы инвалидларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү буенча комплекслы хезмәт күрсәтүгә кагылышлы нормаларны төгәлләштерү буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителде.

Ачык Татарстан порталының халык экспертизасы бүлегендә закон проектлары турында гражданнар тарафыннан фикер алышу каралган.

Иҗтимагый палата әгъзаларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында, аның комитетлары эшендә даими катнашу тәҗрибәсе ныгыды.

Мондый кызыксынулар, бер яктан, кабул ителә торган карарларның логикасын халыкка яхшырак аңларга, икенче яктан, җәмгыять үсешен күзаллауны исәпкә алып, үз позицияңне һәм тиешле тәкъдимнәрне вакытында формалаштырырга мөмкинлек бирә.

**Гавами өстенлекләрне еллык формалаштыру турындагы** инициатива республика Хөкүмәте тарафыннан хупланды һәм күп еллар дәвамында уңышлы гамәлгә ашырыла. Аның нигезен республика башкарма хакимият органнары тарафыннан норматив хокукый актлар әзерләгәндә һәм аларны гамәлгә ашырганда, идарәчел карарлар кабул иткәндә **җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу** өчен халыктан сораштыру тәшкил итә.

2024 елда «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый хәлен халык тарафыннан бәяләү», «халыкның социаль өлкәдәге хезмәтләрнең сыйфатыннан канәгать булуын бәяләү», «җәмәгать иминлеге проблемалары

һәм Татарстан Республикасы хокук саклау органнары эшчәнлеге турында җәмәгатьчелек фикерен бәяләү» буенча социологик тикшеренүләр үткәрелде.

Күрсәтелгән тикшеренүләр нигезендә 2025 елга гавами өстенлекләрнең реестры билгеләнде, аның нигезендә республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан максатчан чаралар комплексы гамәлгә ашырылды.

**Иҗтимагый палатаның һәм социаль блок министрлыкларының** (сәламәтлек саклау, мәдәният, мәгариф һәм фән, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, спорт һәм яшьләр эшләре буенча) уртак эшчәнлегенә мисал итеп 2018 елдан гамәлгә ашырыла торган **максатларны һәм бурычларны гавами формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле проектын** китерергә була.

Әлеге проект инициатив гражданнарның, экспертларның, министрлыкларның иҗтимагый советлары әгъзаларының тармак эшчәнлегенең бер елга өстенлекләрен формалаштыруда ныклап кызыксынуын күздә тота. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча 27 меңнән артык граждан һәм фикер алышуда катнашучылар, министрлыкларның иҗтимагый советлары тарафыннан 2025 елга 38 гавами максат һәм бурыч билгеләнде, алар ел дәвамында күзәтеп барылды һәм массакүләм мәгълүмат чараларында чагылыш тапты.

Барлык министрларның иҗтимагый палата мәйданчыгында узган гавами максатлар һәм бурычлар үтәлеше турында еллык хисаплары йомгаклары буенча 35 өстенлек тулысынча үтәлгән дип танылды. Мәгариф һәм фән министрлыгына, Спорт министрлыгына һәм Мәдәният министрлыгына 2026 елда өлешчә генә үтәлгән дип танылган өч максатчан күрсәткечкә ирешү эшен дәвам итәргә тәкъдим ителде.

Әлеге проект гражданнарга һәм иҗтимагый оешмаларга, министрлыклар эшчәнлегенең өстенлекләрен (индикаторларын) эшләүдә, аларны гамәлгә ашыру эшенә мониторинг ясауда һәм нәтиҗәлелекне бәяләүдә катнашып, идарә итү процессына актив кушылырга мөмкинлек бирә.

**Республика министрлыкларының һәм ведомстволарының 34 иҗтимагый советы** җәмәгатьчелекнең министрлыклар һәм ведомстволар эшендә катнашуының нәтиҗәле механизмы булуын күрсәтте. Алар составына Иҗтимагый палата һәм эксперт бергәлеге вәкилләрен кертү **проблемалы мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә**, нормалар чыгару эшчәнлегендә һәм стратегик планлаштыруда катнашырга мөмкинлек бирә.

Мисалга, 2025 елда Дәүләт торак инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет 2026 елга күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга дәүләт лицензия контроле вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе гамәлгә ашырганда закон белән




саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар салу) куркынычын профилактикалау программасы проекты буенча фикер алышты.

Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәрге чорга халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру буенча 2025 – 2030 елларга (II этап) Татарстан Республикасы чаралары планын раслау турында» күрсәтмә проектын хуплады.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә кәрәзле элемтәнең сыйфатын һәм аннан файдалану мөмкинлеген мониторинглау платформасын эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә бәйле мәсьәләләрне карады, ә Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет «2024 – 2026 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү стратегиясе»н карады һәм, нәтиҗәдә, мәгълүмат платформасы – Фәнни-консультатив үзәк төзүне тәкъдим итте. Архив эше буенча дәүләт комитеты һәм Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршындагы иҗтимагый советларның уртак утырышы коррупциягә каршы эшчәнлек мәсьәләләрен карауга багышланды, аның кысаларында ведомстволар арасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында ике яклы килешү имзаланды.

**Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының иҗтимагый советлары** зур мөмкинлекләргә ия.

2025 елда 44 иҗтимагый совет эшләп килде, аларның составында 675 кеше хезмәт куйды. Казан шәһәре Иҗтимагый советы да үз эшчәнлеген башлап җибәрде.

Әлеге иҗтимагый советлар **хакимият органнары һәм җәмгыять арасында гражданга иң якын дәрәҗәдә – муниципалитет дәрәҗәсендә – үзара хезмәттәшлекне** тәэмин итү өчен төп институт булып торалар.

Җәмәгать эшлекләләрен һәм коммерциягә карамаган оешмаларны территорияләрне перспективалы үстерү мәсьәләләренә җәлеп итү һәм хакимият эшчәнлегенә гражданнар контролен оештыру муниципалитетларның нәтиҗәле үсешенә, хакимиятнең ачыклыгын һәм хәбәрдарлыгы дәрәҗәсен арттыруга, гражданнарның тотрыклылыгын һәм социаль хәлен яхшыртуга ярдәм итә.

2024 – 2025 елларда иҗтимагый советлар эшчәнлеген җайга сала торган документлар актуальләштерелде һәм яңартылды. Вәкаләтләр чоры тәмамлану сәбәпле Балтач, Кама Тамагы, Чүпрәле, Менделеевск, Мөслим, Саба районнарында һәм Чаллы шәһәрендә Иҗтимагый совет составлары яңартылды.

2025 елның сентябрендә 25 муниципаль район иҗтимагый советларының 53 әгъзасы җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатлары итеп сайланды.

2025 елда иҗтимагый советлар эшчәнлеге берничә төп юнәлештә алып барылды:



– МХОда катнашучыларга, Татарстан шефлыкка алган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләргә гуманитар ярдәм;

– 14 сентябрьдә тавыш бирү көнендә үткәрелгән сайлауларга җәмәгать контроле, Иҗтимагый палатаның җәмәгать күзәтчелеге штабы 21 муниципаль районның иҗтимагый советлары белән элемтәдә торды;

– халык белән эшләү һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, лидер – Бөгелмә районы Иҗтимагый советы, ул 115 гражданны кабул итте;

– коммерциягә карамаган оешмалар белән хезмәттәшлектә социаль әһәмиятле чаралар оештыру һәм уздыру.

Башкарылган эшләрдән уңышлы мисаллар:

– «Без бергә» иҗтимагый оешмалар фестивале – Нурлат районы Иҗтимагый советы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган уникаль проект. 2025 елда ул өченче тапкыр уздырылды һәм 20дән артык җирле коммерциягә карамаган оешмаларны җыйды;

– Зеленодольск шәһәрендә «XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы «Полукамушки» тарихи кварталын торгызу» проекты каршылыклы башланган вазгыятьне конструктив юнәлешкә, белгечләрнең һәм битараф булмаган гражданнарның кызыксынуына үзгәртте;

– «Пасека единства и гармонии» - күршелек мөнәсәбәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән проект, ул «Татарстан – Яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең Аксубай территориаль бүлеге белән берлектә тормышка ашырыла, «Күрше-Фест» ишегалды территорияләре республика конкурсында җиңү яулады;

– «Яшь әти-әниләр мәктәбе» – «Татарстан хатын-кызлары» региональ иҗтимагый оешмасының Азнакай районындагы бүлеге белән берлектә уңышлы гамәлгә ашырыла торган, яшьләрдә ата-ана компетентлыгын арттыруга һәм бала тәрбияләү күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән 10 еллык тарихы булган проект, ул 2024 елда гражданжәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантына ия булды.



2025 елда иҗтимагый советларның бер өлеше җирле норматив хокукый актларны эшләгәндә эксперт һәм консультатив орган ролендә чыгыш ясады. Баулы районында 93 проект каралды, шул исәптән Баулы шәһәре һәм Баулы районы уставына үзгәрешләр кертелде. Мөслим һәм Яңа Чишмә районнары советлары проектны карауда һәм 2026 елга бюджетларны раслауда, Нурлат районы советы — спорт һәм мәгариф объектларына өч мактаулы исем һәм ике персональ исем бирүдә, Буа районы советы – стационар булмаган сәүдә объектларын төзекләндерү һәм урнаштыру кагыйдәләрен эшләүдә, Арча районы советы муниципаль контрольнең дүрт төре буенча хокук бозуларны профилактикалау программаларын килештерүдә катнаштылар.

Апрель аенда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының һәм Азнакай муниципаль районы Иҗтимагый советының киңәйтелгән утырышы булды, анда 8 районның (Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Мөслим, Сарман, Ютазы) иҗтимагый советлары вәкилләре катнашты. Программага патриотик тәрбиянең уңышлы тәҗрибәләрен тәкъдим итү, конструктив диалог, муниципалитетлар арасында тәҗрибә уртаклашу кертелгән иде.

2025 елда граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясенә лаек булганнар арасында Азнакай районы Иҗтимагый советы рәисе Л.М. Әхмәдишина да бар иде. Ул  Татарстан Республикасында иҗтимагый советлар институтын төзүнең башлангычында торган кеше.

Шул ук вакытта кайбер муниципаль берәмлекләрдә советлар иҗтимагый процесслардан «читтә» тора, муниципаль хакимият ярдәмен тоймыйлар. Болар исә 2026 елның көзендә Иҗтимагый палата тарафыннан карауга алыначак.

Гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүгә **кеше хокуклары, бала хокуклары һәм эшкуарлар хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтлары** зур өлеш кертә.  Иҗтимагый палатаның вәкаләтле вәкилләр институты белән **партнерлык мөнәсәбәтләре** көнүзәк мәсьәләләрне тирәнрәк өйрәнергә, алар буенча халык белән фикер алышырга һәм гомумиләштерергә, системалы хәл итү чараларын күрергә ярдәм итә.




Җәзаларны үтәтү оешмаларында кеше хокукларын яклау һәм җәмәгать контроле системасында мөһим рольне закон чыгаручы **җәмәгать күзәтчелеге комиссияләренә** тапшырды. Җәмәгать күзәтчелеге комиссияләренең эшчәнлеген формалаштыруны һәм тәэмин итүне Иҗтимагый палата гамәлгә ашыра.

Җәмәгать күзәтчелеге комиссияләре эше **Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә**  алып барылды. 2025 елда Иҗтимагый палатаның хокук мәсьәләләре һәм җәмәгать контроле комиссиясе әгъзасы Ә.Г. Гайнетдинов җитәкчелегендәге Җәмәгать күзәтчелеге комиссиясенең алтынчы составы үз эшен төгәлләде. Аңа Мөселманнарның Диния нәзарәте, Рус православие чиркәвенең Татарстан митрополиясе, «Ярдәм» хәйрия фонды, «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге»

коммерциягә карамаган автоном оешмасы вәкилләре, шулай ук төрле юнәлешләр буенча белгечләр кертелгән иде.

2022 – 2025 елларда гражданнарның 1400дән артык мөрәҗәгате каралды. Туганнары һәм якыннары мәҗбүри тоту урыннарында булган гражданнар атна саен кабул ителде. Еш кына гражданнар яшәү шартлары, тиешле медицина дәвалануы күрсәтү, җәзаны йомшарту, гамәлдәге законнарга аңлатмалар бирү һәм башка мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иттеләр. Шулай ук кайнар линия телефон номеры да эшләп килә, аның турында мәгълүмат колонияләрдә, изоляторларда, полиция бүлекләрендә һәм психиатрия учреждениеләрендә урнаштырылды.

Өч ел эчендә Татарстан Республикасы Җәмәгать күзәтчелеге комиссияләре әгъзалары Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәте Татарстан буенча идарәсенең мәҗбүри тоту урыннарына 250 тапкыр барды. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән полиция бүлекләрендә һәм Казан шәһәренең махсус кабул итү урыннарында, Казан, Бөгелмә, Әлмәт, Менделеевск, Түбән Кама, Чаллы, Лаеш, Алексеевск, Чистай, Зеленодольск, Балык Бистәсе вакытлыча тоту изоляторларында, Чаллы шәһәренең чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгендә җәмәгать контроле буенча эш алып барылды.

Җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе хөкем ителгәннәр ресоциализациясе һәм адаптациясе, мәҗбүри тоту урыннарында хәйрия һәм гуманитар ярдәм күрсәтү мәсьәләләрендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма белән хезмәттәшлек итте. «Хөкем ителгәннәрне пробацияләү турында» килешү нигезендә 2025 елда 120 дән артык хөкем ителүчегә вакытлыча яшәү урыны бирелде һәм эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтелде.

2025 елда җиденче составтагы Җәмәгать күзәтчелеге комиссиясе төзелде, аңа устав буенча кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны яисә яклауга ярдәм итүне максат итеп куйган гомумроссия һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләреннән 12 вәкил керде.



**Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы һәм регионнарның иҗтимагый палаталары белән партнерлык мөнәсәбәтләре** иҗтимагый үсеш мәсьәләләрен актуальләштерергә, аларны хәл итүдә бергәләп алымнар эшләргә, иң яхшы тәҗрибәләр белән алмашырга мөмкинлек бирә.




Гыйнварда ТР Иҗтимагый палатасы әгъзалары Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының территориаль үсеш, шәһәр мохите һәм инфраструктура комиссиясе рәисе А. Максимов белән очрашты. «Безнең ишегалды» проектын һәм шәһәр мохитен төзекләндерү буенча «Парклар һәм скверлар» программасын гамәлгә ашыруда катнашуның актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышу булды. Шулай ук экотуризмны һәм элекке архитектура ядкарьләре буенча турист маршрутларын үстерүнең, муниципаль берәмлекләрнең инфраструктура объектлары эшчәнлегенең, мәгариф челтәрен һәм башкаларны үстерүнең төрле аспектлары каралды.

Май аенда ТР Иҗтимагый палатасының хокукый мәсьәләләр һәм җәмәгать контроле комиссиясе Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының территориаль үсеш, шәһәр мохите һәм инфраструктура комиссиясе белән берлектә «Татарстан Республикасы территориясендә индивидуаль мобильлек чараларын куллану тәҗрибәсе» темасына түгәрәк өстәл үткәрде.

«Татарстанда инклюзив тәҗрибәләрне үстерү» июль аенда республика Иҗтимагый палатасында узган түгәрәк өстәлдә Россия Иҗтимагый палатасының социаль партнерлык, инклюзив тәҗрибәләргә булышлык һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисенең беренче урынбасары, «Диана Гурцкаяның

«Йөрәк кушуы буенча» сукыр һәм начар күрүче балаларга ярдәм хәйрия фонды» коммерциягә карамаган оешмасының попечительләр советы президенты Д. Гурцкая катнашында каралды. Анда сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә инклюзив белем бирү, мәдәният һәм социаль адаптация мәсьәләләре буенча фикер алышынды.




ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы Ольга Павлова составка кергән Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының территориаль үсеш, шәһәр мохите һәм инфраструктура комиссиясе белән берлектә августта «Кече шәһәрләрне һәм тарихи җирлекләрне үстерү» Бөтенроссия форумы кысаларында «Терәк торак пунктлар инфраструктурасын ныгыту – Россиядә территорияләрне үстерүгә яңача караш» дигән түгәрәк өстәл уздырылды. Анда терәк торак пунктларның инфраструктурасын ныгыту мәсьәләләре – Россиядә территорияләрне үстерүгә яңача якын килү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. Моннан тыш, Алабугада түгәрәк өстәлдә катнашучылар «Кече шәһәр – чын Россия. Милли үзенчәлек һәм милли үзаң остаханәсе» темасына сөйләштеләр.

ТР Иҗтимагый палатасы делегациясе апрельдә Ханты-Мансийскта узган VI Бөтенроссия милли бердәмлек форумында катнашты. Форумда ике палата арасында төбәкара элемтәләрне ныгыту һәм граждан инициативалары өлкәсендә уңышлы тәҗрибәләр белән алмашу турында килешү имзаланды. Аны гамәлгә ашыру кысаларында Ханты-Мансийск делегациясе Казанда булып китте һәм коммерциягә карамаган оешмаларның иң яхшы тәҗрибәләре белән танышты.



Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы делегациясе октябрь аенда «Россия» милли үзәгендә узган «Бергәлек» («Сообщество») форумында катнашты.

Октябрьдә Мәскәүдә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының милләтара, динара мөнәсәбәтләр һәм миграция буенча комиссиясе тарафыннан оештырылган «Яшьләрне деструктив контенттан яклауда диннең роле» һәм «Глобаль тенденцияләр контекстында экстремизмга каршы тору» темаларына түгәрәк өстәлләрдә Татарстан Иҗтимагый палатасының традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклап калу һәм ныгыту буенча комиссиясе рәисе Р. Патеев катнашты. Ул «Ислам бергәлекләренең социаль-мәдәни трансформацияләре: радикальләшү мәсьәләләре һәм аларга каршы тору проблемалары» дигән доклад тәкъдим итте.

2025 елда Иҗтимагый палата институциональ яңару һәм заманча таләпләргә җайлашу этабын узган төп гомумроссия институтлары – **«Белем» («Знание») Россия җәмгыяте һәм Кызыл хач белән хезмәттәшлеген** конструктив үстерүне дәвам итте.

Россиянең «Белем» («Знание») җәмгыяте үсеп килүче буынны агарту һәм тәрбияләү өлкәсендә әйдәп баручы партнерларның берсенә әверелде. 45 меңләп кеше катнашында 1000 нән артык мәгърифәт чарасы үткәрелде. Эшләү рәвешләре төрлелеге лекцияләр һәм интеллектуаль уеннардан алып кино күрсәтүләргә һәм дискуссия мәйданчыкларына кадәр булды. Аудитория белән эшләүгә Татарстаннан 300 дән артык лектор җәлеп ителде, алар арасында махсус хәрби операция ветераннары, әйдәп баручы югары уку йортлары вәкилләре, педагоглар, журналистлар, шулай ук башкарма һәм закон чыгару хакимияте органнары хезмәткәрләре бар иде. Уртак эштә аерым игътибар ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә һәм тарихи хәтерне саклауга бирелде.

Россия Кызыл хачының региональ бүлеге белән багланышлар, беренче чиратта, гуманитар ярдәм күрсәтү, кризис хәлләрендә гражданнарга ярдәм итү, шәфкатьлелек хезмәтләрен үстерү, сәламәтлекне саклау һәм беренче ярдәмне өйрәтү программаларын гамәлгә ашыру кысаларында урнаштырылды.

«Алдынгылар хәрәкәте» республика бүлеге белән берлектә беренче ярдәм күрсәтү буенча 4 региональ чемпионат оештырылды. 2025 елда чемпионат «ОЭЗ ППТ «Алабуга» АҖ мәйданчыгында узды һәм Татарстан Республикасының 18 муниципаль берәмлегеннән 40 команданы (240 кеше) берләштерде.

# 3. Дәүләт ярдәме чаралары

Граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен тапшырганда Р.Н. Миңнеханов: «Татарстан гадәттәгечә граждан җәмгыяте институтларын үстерү буенча алдынгы регионнар исәбенә керә. Бездә иҗтимагый берләшмәләр һәм инициативалар хуплана, коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудырыла, грант конкурслары гамәлгә ашырыла», – дип билгеләп үтте.

**Республикада коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү системасы комплекслы** эшли һәм ул граждан җәмгыятенең тотрыклы экосистемасын булдыруга, аның гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрүдә катнашуына, социаль инклюзиядән һәм ватанпәрвәрлек тәрбияләүдән алып регионның инвестицион климатын һәм фәнни-мәгариф мөмкинлеген үстерүгә кадәр өстенлекле бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

**Коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт гранты ярдәме** иҗтимагый үсешнең билгеле бер өстенлекләре буенча эшчәнлекне кызыксындыруның төп формаларының берсе булып тора.



Татарстан Республикасында грантлар 2010 елдан бирле бирелә. Вакытлар узу белән грант бирүче ведомстволар саны һәм конкурсларга бүлеп бирелә торган суммалар артты. 2022 елда эшне тагын да нәтиҗәлерәк оештыру максатында барлык акчаларны туплау һәм бердәм грант операторын билгеләү турында карар кабул ителде. Шулай итеп, гражданнарга яшәү шартларын тудыру һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту, граждан җәмгыяте институтларын үстерүдә коммерциягә карамаган оешмаларның ролен арттыру, дәүләт ярдәме күрсәтү һәм конкурста катнашучыларның социаль әһәмиятле эшчәнлеген үстерү максатларында граждан җәмгыятен үстерүгә тәүге тапкыр **Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә бердәм конкурс** үткәрелде.

2025 елда Конкурска Татарстанның 43 муниципаль берәмлегеннән һәм Россиянең 30 субъектыннан 413 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма гаризасы теркәлде.

Конкурс социаль әһәмиятле өстенлекне чагылдырган 21 номинация буенча үткәрелде:

– гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау;

– гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

– гаиләгә, ана булуга, ата булуга һәм балачакка ярдәм итү;

– «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 311 статьясында каралган эшчәнлек төрләрен үз эченә алган яшьләр проектларына ярдәм итү;

– яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалау;

– балаларда һәм яшьләрдә ватанпәрвәрлек тәрбияләү;

– фән, мәгариф, мәгърифәт өлкәсендәге проектларга ярдәм итү;

- мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге проектларга ярдәм итү;

- мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә яшь талантларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

– тарихи хәтерне саклау, тарихны үзгәртү омтылышларына каршы тору;

– кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, шул исәптән тоткыннарның хокукларын яклау;

– әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау;

– халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү;

– милләтара һәм динара татулыкны ныгыту, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм яклау;

– татар милли мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү;

– Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру;

– чит ил гражданнары (мигрантлар) адаптациясенә ярдәм итү;

– Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасын саклау;

– иҗтимагый дипломатияне үстерү һәм ватандашларга ярдәм итү;
– граждан җәмгыяте институтларын үстерү;
– махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм итү.

Эксперт бәяләве нәтиҗәләре буенча 155 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма, шул исәптән Россия Федерациясенең 9 субъектыннан 10 проект җиңүче булды.

Бирелә торган грантлар суммасы түбәндәгечә бүленде:
– 27 коммерциягә карамаган оешмага – 2 млн сумнан артык;
– 38 коммерциягә карамаган оешмага – 1 млн сумнан алып 2 млн сумга кадәр;
– 43 коммерциягә карамаган оешмага – 500 мең сумнан алып 1 млн сумга кадәр;
– 47 коммерциягә карамаган оешмага – 500 мең сумга кадәр.




Грант күләмнәре 29 668 сумнан алып 2 251 000 сумга кадәр булды. Грантларны гамәлгә ашыру срогы – 1 ел.

Конкурс акчаларының гомуми исәбе **158,3** млн сум тәшкил итте (**88,3** млн сум республика бюджетыннан, 70 млн сум – Президент грантлары фонды финанслашуы хисабына бүлеп бирелде).

Республика районнары буенча коммерциягә карамаган оешмалар активлыгы таблицада күрсәтелә.

| № | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре | Гаризалар саны | Җиңүчеләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Казан | 171 | 86 |
| 2 | Чаллы | 18 | 7 |
| 3 | Чистай | 12 | 4 |
| 4 | Кукмара | 10 | 5 |
| 5 | Азнакай | 9 | 1 |
| 6 | Әлмәт | 7 | 2 |

| № | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре | Гаризалар саны | Җиңүчеләр саны |
|---|---|---|---|
| 7 | Спас | 7 | 2 |
| 8 | Нурлат | 6 | 4 |
| 9 | Әлки | 6 | 3 |
| 10 | Түбән Кама | 6 | 3 |
| 11 | Алексеевск | 6 | 2 |
| 12 | Арча | 6 | 2 |
| 13 | Зеленодольск | 6 | 2 |
| 14 | Баулы | 5 | 2 |
| 15 | Бөгелмә | 5 | 1 |
| 16 | Буа | 4 | 1 |
| 17 | Чүпрәле | 4 | 1 |
| 18 | Зәй | 4 | 1 |
| 19 | Лениногорск | 4 | 1 |
| 20 | Питрәч | 4 | 0 |
| 21 | Әгерҗе | 3 | 2 |
| 22 | Апас | 3 | 1 |
| 23 | Балтач | 3 | 1 |
| 24 | Менделеевск | 3 | 1 |
| 25 | Сарман | 3 | 1 |
| 26 | Биектау | 3 | 0 |
| 27 | Лаеш | 3 | 0 |
| 28 | Кайбыч | 2 | 2 |
| 29 | Аксубай | 2 | 1 |
| 30 | Алабуга | 2 | 1 |
| 31 | Теләче | 2 | 0 |
| 32 | Ютазы | 2 | 0 |
| 33 | Әтнә | 1 | 1 |
| 34 | Минзәлә | 1 | 1 |
| 35 | Яңа Чишмә | 1 | 1 |
| 36 | Саба | 1 | 1 |
| 37 | Чирмешән | 1 | 1 |
| 38 | Кама Тамагы | 1 | 0 |
| 39 | Мамадыш | 1 | 0 |
| 40 | Балык Бистәсе | 1 | 0 |
| 41 | Тәтеш | 1 | 0 |
| 42 | Тукай | 1 | 0 |
| 43 | Актаныш | 0 | 0 |
| 44 | Югары Ослан | 0 | 0 |
| 45 | Мөслим | 0 | 0 |
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ:** | | **341** | **145** |

Моннан тыш, 2017 елдан башлап республиканың коммерциягә карамаган оешмалары ел саен грантларга федераль конкурсларда катнаша. 2025 елда 376 оешма **Президент грантлары фонды конкурсына** гариза бирде һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның 64 проекты җиңүче дип табылды, грантларның гомуми суммасы **136,7** млн сум тәшкил итте.

11 районның (Актаныш, Әтнә, Балтач, Биектау, Зәй, Кама Тамагы, Минзәлә, Балык Бистәсе, Тәтеш, Тукай, Ютазы районнары) коммерциягә карамаган оешмалары гариза бирү кампаниясендә катнашмады.

Территорияләр, җиңүчеләр саны һәм коммерциягә карамаган оешмалар алган акчаларның күләме таблицада күрсәтелә.

| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре | Җиңүче коммерциягә карамаган оешмаларның проектлары саны | Гомуми сумма, сумей |
|---|---|---|
| Казан | 40 | 107 506 713,89 |
| Чаллы | 5 | 6 360 480,00 |
| Зеленодольск | 2 | 5 863 329,00 |
| Питрәч | 3 | 5 363 502,90 |
| Әлмәт | 3 | 2 854 358,52 |
| Спас | 3 | 2 283 846,00 |
| Лаеш | 1 | 937 030,00 |
| Югары Ослан | 1 | 924 130,00 |
| Алабуга | 1 | 862 592,00 |
| Апас | 1 | 828 654,00 |
| Түбән Кама | 1 | 828 551,66 |
| Нурлат | 1 | 760 909,00 |
| Теләче | 1 | 694 880,00 |
| Чистай | 1 | 615 150,00 |



**Президент фонды** тарафыннан үткәрелгән **мәдәни инициативалар** конкурслары нәтиҗәләре буенча республиканың социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларының 13 проекты җиңүче дип табылды, грантларның гомуми суммасы **40,4 млн сум** тәшкил итте. Конкурста барлыгы 29 муниципаль берәмлектән 81 коммерциягә карамаган оешма катнашты, җиңүчеләр арасында Казан шәһәреннән (34 907 мең сум суммага 11 проект), Биектау районыннан (4778 мең сум суммага 1 проект) һәм Зеленодольск районыннан (700 мең сум суммага 1 проект) коммерциягә карамаган оешма проектлары бар.

2025 елда **Президент фонды** тарафыннан беренче тапкыр үткәрелгән **экологик һәм табигатьне саклау проектлары** конкурсы нәтиҗәләре буенча Татарстанның 2 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма проекты

җиңүче дип танылды: «Чиста булачак» төбәк яшьләр экологик иҗтимагый оешмасы һәм «Гудсерфинг – Игелекле сәяхәтләр» ихтыярыйлыкны үстерү мәгълүмат үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы. Грантларның гомуми суммасы **6,2 млн сум** тәшкил итте.

**2025 елда Татарстанның социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары үз проектларын гамәлгә ашыруга 341,6 млн сум күләмендә грант акчалары җәлеп итә алды.** Шулардан республика акчалары – 88,3 млн сум, федераль акчалар – 253,3 млн сум.

Коммерциягә карамаган оешмалар проектларына **социаль җаваплы бизнес** та ярдәм итә. **«Татнефть» ГАҖ керткән өлешне** аерым билгеләп үтәргә кирәк. Компания коммерциягә карамаган оешмаларга грант ярдәмен системалы нигездә күрсәтә. 2025 елда «Игелек энергиясе» социаль инициативалар конкурсында **120,7 млн сумга** 65 проект хупланды.

Таблицада территорияләр, коммерциягә карамаган оешмаларның активлыгы һәм грантлар суммасы китерелә.

| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре | Җиңүче коммерциягә карамаган оешмалар саны | Сумма, сумнарда |
|---|---|---|
| Казан | 32 | 71 268 582 |
| Әлмәт | 14 | 23 055 072 |
| Чаллы | 3 | 5 350 305 |
| Нурлат | 2 | 3 249 152 |
| Чистай | 2 | 3 011 230 |
| Питрәч | 1 | 2 999 590 |
| Түбән Кама | 2 | 2 335 090 |
| Спас | 2 | 2 236 149 |
| Азнакай | 2 | 2 107 148 |
| Аксубай | 1 | 2 038 578 |
| Баулы | 1 | 1 358 655 |
| Бөгелмә | 1 | 651 800 |
| Алабуга | 1 | 570 560 |
| Әлки | 1 | 501 760 |

Моннан тыш, 48 республика проекты, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү буенча «РИТЭК» ҖЧҖнән («ЛУКОЙЛ» ГАҖ социаль һәм мәдәни проектлар конкурсы кысаларында) 15 млн сумга грант алды.

**«Россия яшьләре. Грантлар»** конкурсларында яшь гражданнар җиңүче булды һәм социаль проектларга 74,3 млн сум күләмендә грант ярдәме алды (Татарстан акча җәлеп итү буенча топ-5 кә керде).



2014 елдан «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының бер өлеше буларак **«Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» дәүләт ярдәмче программасы** гамәлгә ашырыла. Аны республика бюджетыннан финанслау күләме 2024 – 2027 елларга 1 369,76 млн сум тәшкил итә, шул исәптән 2025 елга – 357,3 млн сум.

Әлеге ярдәмче программа **субсидияләре хисабына** ел саен үткәрелә торган «Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивале, «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләр иҗаты ачык республика телевизион фестивале кебек социаль әһәмиятле проектлар гамәлгә ашырыла. Р. Ваһапов исемендәге халыкара фестиваль, Франкофония көннәре, Яһүд музыкасы фестивале уздырылды.

«Единство», «Хади Атласи. Политик, историк, богослов», «Илһам җырлары», «Неизвестные герои», «Я увижу тебя стихами», «Мой пес» кинопроектлары гамәлгә ашырылды.

Максатчан программалар нигезендә шактый күләмдә бюджет ресурслары **дәүләт бурычларын башкаручы коммерциягә карамаган оешмаларга** җибәрелде.

Әйтик, 22 гомуми белем бирү һәм 19 мәктәпкәчә хосусый оешмага мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга 287,43 млн сум күләмендә субсидия бүлеп бирелде. «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасына мәгариф һәм фән өлкәсендәге чаралар

оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә һәм каплауга 380,99 млн сум күләмендә субсидия бирелде. «Иннополис Университеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасына «Физика-математика алгарышы» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия – 73,4 млн сум, «Татарстан Республикасы Фән һәм технологияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына – 250 млн сум, «Талантлар Университеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасына – 100 млн сум тәшкил итте.

Коммерциягә карамаган оешмаларга «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын торгызу һәм куллану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә экологик проектларга субсидияләр 14,45 млн сум тәшкил итте.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертү аларга яңа мөмкинлекләр ачты. Бу индивидуаль программа кысаларында гражданнарга шартнамә нигезендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр өчен дәүләт компенсациясе бирү өчен сайлап алуда катнашырга мөмкинлек бирә.

2025 ел ахырына реестрга 35 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, авыр тормыш хәлендә калган мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм яшүсмерләргә тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә торган 24 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма кертелде.

2015 елдан, мондый мөмкинлек барлыкка килгәч, реестрга кертелгән дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләр саны 11,6 тапкырга артты. Социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең гомуми санының дәүләтнеке булмаган оешмаларга туры килә торган өлеше 2,3% тан 23,6% ка кадәр артты.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, нәкъ менә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар үзгәрешләрдән курыкмый, алар даими рәвештә социаль инновацияләр кертә, ихтыяҗ булган хезмәтләр күрсәтә.

2025 ел нәтиҗәләре буенча, гомумән алганда, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан 7 146 кешегә хезмәт күрсәтелде, моңа Татарстан Республикасы бюджетыннан 320,8 млн сум акча җибәрелде.

Коммерциягә карамаган оешмаларга инфраструктура ярдәмен күрсәтүдә ресурс үзәкләре мөһим урын алып тора.

**Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итүнең республика ресурс үзәге** (Казан шәһәре, 8 Март ур., 18Б йорты) 2015 елда социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның беренче форумы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә төзелде. Ул 498,6 кв. м мәйданда урнашкан, анда зур булмаган конференц-зал, 10 эш бүлмәсе һәм 36 эш урыны бар. 2018 елгы конкурс нәтиҗәләре буенча бинада 26 оешмага эшчәнлек алып бару мөмкинлеге бирелде.

Үзәк әлеге коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүдән тыш, ул гражданнарны кабул итү, чаралар уздыру өчен мәйданчык та булды.

Хәзерге вакытта бинаны реновацияләү мәсьәләләре хәл ителә, анда бердәм грантооператор урнаштыру турында карар кабул ителде. Бу барлык коммерциягә карамаган оешмалар белән мәгълүмати-методик эшне көчәйтергә, семинарлар, укулар һәм тренинглар, түгәрәк өстәлләр һәм граждан җәмгыятенең барлык субъектлары белән дискуссияләр оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итүгә исәпләнгән ярдәмче программа нигезендә республикада коммерциягә карамаган оешмаларның белем бирүне, консалтингны һәм мондый оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган **6 муниципальара ресурс үзәге** эшләп килә. Алар Казан шәһәрендә («Инновацион үсеш һәм технологияләр трансферы үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы), Әлмәттә («Коммерциягә карамаган оешмалар остаханәсе» коммерциягә карамаган секторга ярдәм итү ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы), Чаллыда («Горизонт» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы), Кукмарада («Вектор» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы), Буада («Буа Грант» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы), Чистайда («Бердәмлек» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы) урнашкан. Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен 6,8 млн сум күләмендә субсидия бүлеп бирелә. Үзәкләрне урнаштыру өчен шартлар муниципаль берәмлекләр тарафыннан тәэмин ителә.

Ел дәвамында әлеге үзәкләр тарафыннан 660 консультация оештырылды һәм 195 семинар уздырылды. Алар шулай ук республика һәм федераль грант конкурсларында катнашу өчен тапшырылган гаризаларга аудит үткәрүдә катнаша, теркәү гамәлләрендә (социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманы төзегәндә, гамәлгә кую документларына, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр керткәндә) ярдәм итә. Алар булышлыгы белән 2025 елда 35 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма теркәлде.

Татарстан Республикасының күпмилләтле хәрәкәте өчен гамәлдәге ресурс үзәге булып 1999 елдан бирле Казанда эшләп килүче Халыклар дуслыгы йорты хезмәт итә, ул республика бюджетыннан финанслана. Эшчәнлек масштаблары, эш мөмкинлекләре һәм эчтәлеге буенча бу – Россиядә бу өлкәдәге иң алдынгы тәҗрибәләрнең берсе. Биредә Татарстан халыклары Ассамблеясына керә торган барлык милли-мәдәни оешмалар урнашкан һәм эш алып бара.

Шулай ук муниципаль дәрәҗәдә – Чаллы, Азнакай, Буа, Лениногорск, Менделеевск, Түбән Кама, Нурлат һәм Тәтештә 8 халыклар дуслыгы йорты

эшли. Апас, Чүпрәле, Яңа Чишмә һәм Спас районнарында, мәдәният учреждениеләренең структур бүлекчәләре буларак, халыклар дуслыгы үзәкләре ачылды.

2018 елдан бирле республика бюджеты акчасына А.С. Пушкин исемендәге мәдәни үзәк эшли, ул рус этномәдәни оешмаларының ресурс базасы булып тора, ә 2019 елдан керәшен мәдәни проектларын гамәлгә ашыручы Я.Е. Емельянов исемендәге Мәдәни үзәк эшчәнлек алып бара.

Традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне торгызу **дини оешмаларның игътибар үзәгендә** тора. Белгәнебезчә, дин дәүләттән аерылган, әмма җәмгыятьтән түгел.

Дини оешмалар хакимият органнары белән берлектә киң җәмәгатьчелек катнашында күп кенә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыра. Аларның ресурс базасы сизелерлек ныгыды. Хәзерге вакытта республикада ТР мөселманнары Диния нәзарәте составына керүче 1588 мәчет һәм 571 православие объекты эшләп килә. Борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчегенең изге дини урыннарын торгызу, Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу һәм Болгар ислам академиясен төзү әһәмиятле вакыйга булды. Дәүләтнең, бизнесның һәм гражданнарның финанс ярдәме белән «Яңарыш» фонды тарафыннан тормышка ашырылган әлеге һәм башка проектлар халкыбызның бай тарихи-мәдәни мирасын ача, традицион рухи кыйммәтләрне ассызыклый, динара конструктив хезмәттәшлек маягы булып хезмәт итә.

**«Созвездие – Йолдызлык»** фестиваль хәрәкәте» иҗтимагый оешмасының эшчәнлеген һәм үсешен күрсәтүче матур мисал тарихи Алафузов сарае бинасында урнашкан шул ук исемдәге дәүләт театры ачылу булды. Әлеге театр яшь талантларны барлау буенча конкурс чаралары өчен дә, илнең әйдәп баручы вузларын тәмамлап кайткан хәрәкәттә тәрбияләнүчеләрне эшкә урнаштыру өчен дә ресурс мәйданчыгы булды. Хәзер бу – яшьләрнең иҗади проектларын гамәлгә ашыру драйверларының берсе.



Шулай ук Татарстанның иҗат лабораторияләре һәм заманча репертуар булдыру кысаларында үз идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлеге алган яшь иҗатчылары өчен ресурс үзәге – «Живой город» заманча сәнгатькә ярдәм фонды һәм аның ике театраль мәйданчыгы – МОÑ һәм «Особняк Демидова» эшчәнлеген дәвам итте.

Граждан инициативаларын бүләкләү һәм граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында 2015 **елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе** гамәлгә куелды.



Узган чорда премиягә 977 кандидат тәкъдим ителде, 49 оешма һәм 32 җәмәгать эшлеклесе аның лауреатлары булды.

2025 елда премия түбәндәгеләргә бирелде:

– Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе Л.М. Әхмәдишинага;

– «Россия ветераннар берлеге» гомумроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе, Татарстан Республикасында «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең региональ бүлеге башлыгы генерал-майор А.И. Бородинга;

– К(И)ФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының Татарстан тарихы, антропология һәм этнография кафедрасы профессоры Т.А.Титовага;

– «Ак Барс Созидание» хәйрия фондына;

− «Татарстан Республикасы мордваларның милли-мәдәни автономиясе» региональ иҗтимагый оешмасына;

«Татарстан Республикасы диңгез җыены» төбәк иҗтимагый оешмасына;

− «Хезмәт Кызыл байрагы орденлы Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татар региональ иҗтимагый оешмасына;

– «Россия юристлар ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә.

Премия күләме физик затлар өчен – 500 мең сум, оешмалар өчен 800 мең сум тәшкил итте.

Коммерциягә карамаган секторның иң яхшы тәҗрибәләрен яктыртуга игътибарны җәлеп итү максатларында республикада **социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс** уздырыла. 2025 елда конкурс 5 номинация буенча үткәрелде: «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырткан телесюжет (яисә телетапшыру)», «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырткан радиосюжет (яисә радиотапшыру)», «Басма массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырткан язма», «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырткан язма», «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырткан мультимедиа проекты».

Конкурста массакүләм мәгълүмат чараларыннан 15 автор җиңүче булды. Гомуми приз фонды 500 мең сумны тәшкил итте.

# 4. Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы

**Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы** дәүләт белән үзара мөнәсәбәтләрдә коммерциягә карамаган секторның эшчәнлеген һәм позициясен берләштерүче, аларның хезмәттәшлеге һәм иҗтимагый әһәмиятле карарлар чыгару өчен мәйданчык буларак танылды.

Иҗтимагый палатаның соңгы елларда эшләгән элеккеге составларына катлаулы пандемия һәм махсус хәрби операция уздыру шартларында дәүләт һәм җәмгыятьнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә туры килде. **Иҗтимагый палата үзе дә, тулаем алганда, коммерциягә карамаган оешмалар да, бер яктан, граждан татулыгын һәм тотрыклылыкны тәэмин итүгә ярдәм итеп, икенче яктан, җәмгыять үсешенең ресурс оешмалары ролендә чыгыш ясап, граждан башлангычлары һәм социаль башлангычлар тәкъдим иттеләр.**



2026 елның 22 гыйнварында яңа, VIII состав эшчәнлеге башланды, аңа аеруча эшлекле һәм абруйлы 60 җәмәгать эшлеклесе керде.



Мәсьәләләрнең актуальлеген исәпкә алып, Палата структурасында профильле 8 комиссия һәм 7 эшче төркем оештырылды, төрле өлкәләрдән 50дән артык белгечне туплаган экспертлар пулы булдырылды.

Эшчәнлекнең иң уңай якларын һәм тупланган тәҗрибәне саклап калган килеш, Палата составын яңарту, якындагы өч елга республика халкының реаль ихтыяҗларына һәм Татарстан үсешенең стратегик бурычларына юнәлдерелгән системалы эш алып барылачагын күрсәтә.

2025 елда Иҗтимагый палата республика Рәисен һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына сайлауларда **тавыш бирү процессының ачыклыгын һәм аның нәтиҗәләренә ышанычны тәэмин итүгә** ярдәм итте.

Тавыш бирүгә җәмәгать контроле буенча координация советы төзелде, аңа ТР Иҗтимагый палатасы, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, шулай ук Сайлауларны иҗтимагый күзәтеп тору штабы керде. Эшчәнлек Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән тыгыз элемтәдә алып барылды.

Күзәтеп торуны тормышка ашыру өчен, иҗтимагый күзәтүчеләр сайлап алынды һәм өйрәтелде. Аларны әзерләгәндә төп игътибар гамәли күнекмәләргә, законнардагы яңалыкларны белүгә, ялган хәбәрләргә оператив җавап бирә белүгә, фото- һәм видеотеркәүне дөрес оештыра белүгә һ.б. ясалды. ТР Иҗтимагый палатасы 2710 даими сайлау участогына, 40 территориаль сайлау комиссиясенә, 4 вакытлы сайлау участогына (ТР буенча УФСИН тикшерү изоляторлары) һәм Мәскәүдәге 1 экстерриториаль участокка 2755 күзәтүче җибәрде.




Тавыш бирү көнендә ТР Иҗтимагый палатасында сайлауларны иҗтимагый күзәтеп тору штабы һәм Чара күрү үзәге эшләде. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегеннән Иҗтимагый совет рәисләре һәм әгъзалары белән 4 онлайн тоташу гамәлгә ашырылды. Онлайн тоташуларда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурская, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе Е.И. Кузьмичева, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Граждан җәмгыятен үстерү һәм кеше хокуклары советының сайлауларны мониторинглау буенча эш төркеме әгъзасы А.А. Малькевич катнашты. Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы белән онлайн тоташу булды. Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының тавыш бирүгә җәмәгать контроле буенча эш төркеме җитәкчесе М.Григорьев республикада җәмәгать күзәтүе процессын оештыруның югары дәрәҗәдә оештырылуын ассызыклады.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе – **коммерциячел булмаган сектор вәкилләрен укыту, системалы рәвештә аларның компетенцияләрен арттыру** һәм

тәҗрибә алмашу өчен мәйданчыклар оештыру. Бу эш махсус мәгариф проектлары кысаларында да, профильле утырышлар, түгәрәк өстәлләр уздыру һәм бөтенроссия форумнарында катнашу аша да алып барылды.



«Ак Барс Созидание» фонды тәкъдиме белән «АК БАРС» БАНК ГАҖ Корпоратив университеты белән берлектә «ТР социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларының остазлык мәктәбе» проекты кысаларында дүрт юнәлеш: идарә итү компетенцияләрен үстерү, коммерциягә карамаган яңа оешмалар өчен акселератор, социаль йогынтыны бәяләү һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмада цифрлы компетенцияләр буенча «Социаль үзгәреш лидерлары» программасы гамәлгә ашырылды. Уку нәтиҗәсендә 140 коммерциягә карамаган оешма һәм иҗтимагый оешма җитәкчесе идарә итү күнекмәләрен арттырды. Бу эшнең дәвамы буларак «Социаль өлкәдә иҗтимагый башлангычлар һәм коммерциягә карамаган оешмаларның роле» вебинары үткәрелде.

Казан инновация университеты базасында «Инклюзив белем бирүнең дәвамлы системасы» форумы кысаларында «Социомәдәни инклюзия шартларында традицион кыйммәтләрне формалаштыруның нигезе буларак – гаилә» дигән темага пленар утырыш узды, анда гаилә әгъзаларының сәламәтлеген профилактикалауны гаилә төзелгән вакыттан башлап игътибар үзәгендә тоту мәсьәләләре каралды.

ТР Иҗтимагый палатасы һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт каршындагы Иҗтимагый советның уртак утырышында дарулар белән эш итү мәсьәләләре каралды, шулай ук закон чыгару һәм хокук куллану практикасы өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу булды.

«Сәнгать буларак мода: Татарстан Республикасында мода индустриясенең уңышлары һәм проблемалары» темасы Иҗтимагый палата әгъзалары, ТР Дизайнерлар берлеге вәкилләре һәм Казан дәүләт мәдәният институты вәкилләре арасында фикер алышу предметы булды. Катнашучылар төбәкнең имиджын күтәрүне этник мәдәният аша алып баруның мөһимлеген ассызыклады.

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә багышланган «Никах, гаилә һәм закон: традицион кыйммәтләрне хокукый яктан ныгыту» дип аталган түгәрәк өстәл экспертларны, юристларны, хакимият һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җыйды, алар традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауда гаилә институтының роле, алиментлар һәм никах шартнамәсе мәсьәләләре буенча фикер алышты.

Эшкуарлар бергәлеге белән хезмәттәшлектә бизнесны үстерү, социаль әһәмияткә ия азык-төлек товарларының сыйфаты, коммуналь хезмәтләр өчен түләүне үзгәртү, креатив индустрияләрне үстерү мәсьәләләре каралды. Татарстан Республикасы Кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре ассоциациясе белән берлектә 40 район вәкилләре катнашында «Эшкуарларның иң яхшы иҗтимагый советы» республика конкурсы уздырылды, җиңүчеләр 12 номинациядә билгеләнде. Конкурска йомгак ясаганда Зеленодольск шәһәрендәге Мәдәни үсеш үзәге мәйданчыгында җирле эшкуарларның товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре тәкъдим ителгән күргәзмә оештырылды.

ТР Иҗтимагый палатасы мәйданчыкларында коммерциягә карамаган сектор вәкилләрен укыту һәм алар өчен һөнәри диалог оештыру буенча системалы алып барыла торган эш уңышлы тәҗрибәләрне таратуга һәм иҗтимагый үсешнең актуаль мәсьәләләре буенча эшчәнлекне камилләштерүнең конкрет тәкъдимнәрен эшләргә ярдәм итте.

Күп еллар дәвамында республиканың Иҗтимагый палатасы Россиядә бу өлкәдә танылган лидерларның берсе булып тора.

2022 елдан ул Россия Иҗтимагый палатасы тарафыннан RAEX рейтинг агентлыгы белән берлектә төзелә торган төбәк иҗтимагый палаталары рейтингында беренче өчлеккә керә.

2025 елда ТР Иҗтимагый палатасы гомуми рейтингта **3 урынны** алды (1 урын – Ульяновск өлкәсе, 2 урын – Свердловск өлкәсе).

Шул ук вакытта РФ Иҗтимагый палатасы белән үзара хезмәттәшлекнең активлыгы күрсәткече буенча 1 урында булды һәм медиаактивлык күрсәткечләре, эксперт сораштыруы нәтиҗәләре буенча **беренче унлыкка** керде.

Кайбер юнәлешләр буенча эшне яхшырту да таләп ителә, ТР Иҗтимагый палатасы түбәндәге юнәлешләр буенча беренче унлыктан төшеп калды:

– иҗтимагый күзәтү активлыгы;
– нормалар чыгару активлыгы (алдагы 3 елда кергән иде);
– мәгълүмати ачыклык;
– палата әгъзаларының гавами активлыгы (узган 2 елда кергән);
– матди тәэмин ителеш һәм оештыру эше.

**Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар социаль инновацияләр өчен зур потенциал булып тора.** Бу оешмалар – мөстәкыйль институт, ул социаль өлкәдә башка ике секторның – дәүләтнең һәм бизнесның – эшен тулыландыра һәм аларга төзәтмәләр кертә, җәмгыятьнең тотрыклы үсешен тәэмин итә, граждан башлангычлары һәм кешенең шәхес буларак формалашуы өчен платформа булып хезмәт итә.

Халыкка дәүләт оешмалары белән беррәттән хезмәт күрсәтү хокукын яулау дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан югары дәрәҗәдәге ышанычны, шулай ук социаль өлкәдә өченче сектор институты булуны ассызыклый.

«Ак Барс Созидание» хәйрия фонды (А.Ф. Вәлиева), «Ярдәм-Помощь» иҗтимагый хәйрия фонды (И.Ф. Исмәгыйлев), «Альпари» хәйрия фонды (Н.В. Гыйләҗева), «Игелекле Казан» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (Т.С. Мерзлякова), Анжела Вавилова исемендәге фонд (В.В. Вавилов), «Аталар берлеге» Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмасы (А.Л. Зәһретдинов), **«Кеше приюты»** социаль тернәкләндерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (А.А. Суханов) һәм халык өчен әһәмиятле, абруйлы булган башка социаль юнәлешле коммерциягә карамаган шактый оешмалар югары профессионализм һәм эшчәнлек сыйфаты белән җәмгыятьтә танылу алды.

Алар физик культура, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен алга сөрә, авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә, балалы гаиләләргә һәм инвалид кешеләргә ярдәм күрсәтә, экологик агарту һәм мәдәни мирасны саклау белән шөгыльләнә.

Бу оешмалар гамәлгә ашыра торган проектлар, чыннан да, илдә иң яхшылар рәтендә.



«Игелекле Казан» коммерциягә карамаган автоном оешмасы эшләү дәверендә Казанда инклюзив тәҗрибәләрне үстерүнең иң зур үзәгенә әверелде. Оешма хәйрия фондларын, меценатларны һәм битараф булмаган кешеләрне берләштерә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне социальләштерү, профориентацияләү һәм эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыра.

«Игелекле Казан» коммерциягә карамаган автоном оешмасы төзегән «Тылсым» («Тылсым») инклюзив үзәге «Игелек коды» номинациясендә #МЫВМЕСТЕ-2025 Халыкара премиясе җиңүчесе булды, ул гражданнарның социаль яктан зәгыйфь категорияләренә ярдәм итү проектларына багышланган иде.

2018 елдан Татарстанда мохтаҗларга комплекслы хәйрия ярдәме күрсәтү программасын гамәлгә ашыра торган «Кеше приюты» социаль тернәкләндерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы эшли. Оешма кайнар туклану, азык-төлек җыелмалары, кием-салым, кунып чыгу урыны тәкъдим итә, юридик һәм психологик ярдәм, медицина ярдәме, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны социальләштерү һәм җайлаштыру хезмәтләре күрсәтә.

**Татарстан Республикасы балалар хосписы** дәвалауга бирешми торган авыр чирләре булган балаларга паллиатив ярдәм күрсәтә. 2025 елда «Ак Барс Созидание» хәйрия фонды ярдәме белән тәрбиягә алынган балаларның һәм аларның гаиләләренең ялын оештыруга юнәлдерелгән күчмә чаралар үткәрелде, бу – бәйрәм атмосферасын тудырырга һәм балаларга авыр мизгелләрне оныттырып торырга мөмкинлек бирде.

**«НЕСТРАШНО» хәйрия фонды** яшьләр арасында ВИЧ-инфекцияне профилактикалау, шул исәптән яшүсмерләргә һәм балаларга психологик ярдәм күрсәтү проектларын гамәлгә ашыра.

**«Татарстан Республикасының шикәр авыруы булган кешеләре берләшмәсе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы** 2025 елда шикәр чире булган пациентларга мәгълүмати, психологик һәм хокукый ярдәм күрсәтү эшен дәвам итте. Оешма диабет мәктәпләрен, белгечләр консультациясен оештыра, шулай ук дарулар белән тәэмин итү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр формалаштыруда катнаша.

«Омтылыш» – «Стремление» проекты квалификацияле кадрлар җәлеп итеп, шәһәр яны лагерьларында инклюзив җәйге савыктыру сменалары оештырудан һәм уздырудан гыйбарәт. Ул социаль юнәлешле коммерциягә карамаган берничә оешма тарафыннан үз программалары буенча гамәлгә ашырылды. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән 559 бала өчен барлыгы 7 смена эшләде. Моннан тыш, Казан шәһәренең барлык инклюзив үзәкләрендәге 404 үзенчәлекле баланы җәлеп итәргә мөмкинлек биргән 19 смена оештырылды.

Россия Федерациясенең барлык субъектларында коммерциягә карамаган секторны үстерү потенциалы дәрәҗәсен характерлаучы мәгълүматлар төрле яклап анализлана торган **«Регион-коммерциягә карамаган оешмалар – 2025» өченче сектор рейтингы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы 6 урынны алды.**

Рейтингта регионның үз масштабы йогынтысын минимумга җиткерүче аерым күрсәткечләр өстенлек итә. Асылда, өченче секторның нәтиҗәлелеге, аның тормышка йогынтысы чагыштырыла.

Шул ук вакытта абсолют зурлыклар кулланылган төбәкләр исемлеге дә төзелде, монда коммерциягә карамаган оешмаларның мең кешегә туры килә торган саны түгел, ә гомуми саны һәм гомуми табыш һ. б. исәпкә алына. Әлеге рейтингта Татарстан 3 урында (Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан соң).

**Региональ рейтингта масштабы һәм позициясе буенча беренче 10 регионны чагыштыру**

| Позиция | «Регион-НКО 2025» төбәк рейтингы | Өченче секторның масштабы буенча төбәкләр исемлеге |
|---|---|---|
| 1 | Мәскәү | Мәскәү |
| 2 | Вологда өлкәсе | Санкт-Петербург |
| 3 | Самара өлкәсе | Татарстан Республикасы |
| 4 | Чиләбе өлкәсе | Свердловск өлкәсе |
| 5 | Түбән Новгород өлкәсе | Мәскәү өлкәсе |
| 6 | Татарстан Республикасы | Чиләбе өлкәсе |
| 7 | Ханты-Мансий автоном округы – Югра | Түбән Новгород өлкәсе |
| 8 | Ленинград өлкәсе | Самара өлкәсе |
| 9 | Белгород өлкәсе | Красноярск крае |
| 10 | Красноярск крае | Краснодар крае |

Республика түбәндәге күрсәткечләр буенча беренче унлыкка керә:

− төбәктәге коммерциягә карамаган оешмаларның икътисадый әһәмияте – 4 позиция;

− социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның регион өчен социаль әһәмияте – 5 позиция;

− төбәктә коммерциягә карамаган секторның тотрыклылыгы – 7 позиция;

− төбәктә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар өчен ярдәм чаралары һәм аларның комплекслы булуы – 7 позиция;

− төбәктәге социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар секторына эксперт бәяләмәсе – 10 позиция.

Шул ук вакытта Татарстан түбәндәге күрсәткечләр буенча беренче 20 регион арасына керә алмады:

– социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның эшчәнлек активлыгы;

– регион хакимиятнең социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү дәрәҗәсе;

– социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның медиаактивлыгы.

2023 елдан Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ярдәмендә **коммерциягә карамаган секторның торышын чагылдыра торган «Муниципалитет – коммерциягә карамаган оешмалар» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре рейтингы** әзерләнә. Ул муниципаль хакимият органнарын муниципаль берәмлекләрдәге коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итүне һәм аларны үстерүне кызыксындыруга, граждан җәмгыяте һәм коммерциягә карамаган сектор институтларын үстерүдә Иҗтимагый советларның ролен көчәйтүгә, муниципальара ресурс үзәкләре эшенең нәтиҗәлелеген арттыруга, җирле бергәлекләрнең иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүдә гражданнарның активлыгын арттыруга юнәлдерелгән.

22 муниципаль берәмлекнең социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм программасы күпмедер дәрәҗәдә финанслау белән тәэмин ителгән һәм 2024 елда касса үтәлеше күрсәтелгән чаралар үткәрелгән.

11 муниципаль берәмлек социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга милек ярдәме күрсәткән.

Татарстанның 11 муниципаль берәмлегендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче 23 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма эшли, шуларның 7 Казанда.

Татарстанның 15 муниципаль берәмлегендә иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручы 40 социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма бар, шуларның иң күбе – 22 Казанда теркәлгән.

Татарстан Республикасының 5 муниципаль берәмлегенең рәсми сайтларында өч ел дәвамында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар турында тематик бүлек һәм аларны үстерү, аларга ярдәм итү мәсьәләләре буенча белешмәләр юк. Болар: Әлки, Әлмәт, Арча, Балтач, Яңа Чишмә районнары.

Коммерциягә карамаган оешмаларның медиакиңлектә активлыгы түбән.

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга һәм Иҗтимагый советлар эшчәнлегенә системалы ярдәм күрсәтүче лидерлар төркемендә муниципаль берәмлекләр: Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Спас, Чистай, Кукмара районнары.

Аутсайдерлар: Мамадыш, Кама Тамагы, Ютазы, Әтнә, Тәтеш районнары.

**«Муниципалитет – коммерциягә карамаган оешмалар» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре рейтингы* (2024 елгы йомгаклар)**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре | 11 | Арча | 21 | Минзәлә | 31 | Әгерҗе |
| 2 | Чаллы шәһәре | 12 | Баулы | 22 | Тукай | 32 | Саба |
| 3 | Спас | 13 | Бөгелмә | 23 | Лаеш | 33 | Балтач |
| 4 | Чистай | 14 | Апас | 24 | Алексеевск | 34 | Мөслим |
| 5 | Кукмара | 15 | Алабуга | 25 | Зәй | 35 | Чирмешән |
| 6 | Түбән Кама | 16 | Питрәч | 26 | Сарман | 36 | Актаныш |
| 7 | Азнакай | 17 | Чүпрәле | 27 | Буа | 37 | Биектау |
| 8 | Зеленодольск | 18 | Менделеевск | 28 | Аксубай | 38 | Кайбыч |
| 9 | Әлки | 19 | Нурлат | 29 | Яңа Чишмә | 39 | Югары Ослан |
| 10 | Әлмәт | 20 | Лениногорск | 30 | Теләче | 39 | Балык Бистәсе |
| | | | | | | 40 | Мамадыш |
| | | | | | | 41 | Кама Тамагы |
| | | | | | | 42 | Ютазы |
| | | | | | | 43 | Әтнә |
| | | | | | | 43 | Тәтеш |

Йомгаклау рейтингы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар саны, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү буенча муниципаль программа булу, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма өчен тематик бүлек булу, мөлкәт һәм финанс ярдәме алган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар өлеше, социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрында һәм социаль хезмәтләрне башкаручылар арасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар булу, республика һәм федераль дәрәҗәдәге грантлар бирү конкурсларында катнашу, массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар саны күрсәткечләре буенча урыннарның уртача санын исәпкә алып формалаштырылды.

# 5. Ватанпәрвәрлек, әхлаклылык, гаделлек: граждан җәмгыяте кыйммәтләре

**Җәмгыятьтә Россиянең күпмилләтле халкының традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренә, бай тарихи-мәдәни мирасына таяну илнең үсешенең төп шарты булуын** аңлау дәвам итә.

Моңа чараларга бай булган **Ватанны саклаучылар елы программасы** ярдәм итте. Татарстан җәмгыятьне берләштерүнең югары дәрәҗәсен күрсәтте, аның нигезен ватанпәрвәрлек һәм тарихи хәтер, гаделлек һәм шәфкатьлелек тәшкил итте. **Бөек Җиңүнең 80 еллыгын** бәйрәм итү елы буыннарның дәвамчанлыгын, Россия халыклары батырлыгын һәм бердәмлеген аңлау чоры булды. Республиканың граждан җәмгыяте институтлары әлеге кыйммәтләрнең актив катнашучылары булды, тарихи дөреслекне саклау, яшьләргә патриотик тәрбия бирү, ветераннарга, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә һәрьяклап ярдәм итү проектларын башлап җибәрде.

МХОдә катнашучылар һәм аларның гаиләләре белән «Ватанны саклаучылар» Фонды филиалы тарафыннан зур эш алып барылды, ветераннар бергәлеге булдырылды, аларның иҗтимагый тормышта катнашуы активлашты. Иҗтимагый палата **«Батырлар. Татарстан Геройлары»** программасы (аның составына шулай ук ТР Иҗтимагый палатасы әгъзалары Павлова О.И., Дәүләтшин З.В., Сафиуллин А.Р. керде) кысаларында белем бирү программасында катнашу һәм алга таба аларны идарә эшчәнлегенә җәлеп итү өчен 1 604 гаризадан 46 МХО ветеранын сайлап алды. Иҗтимагый палатаның Патриотик тәрбия бирү, яшьләр һәм ветераннар эшләре комиссиясен программаны тәмамлаган Мөхәммәтҗанов Ә.Р. җитәкләде.

Патриотик тәрбия бирү системасында **«Zа будущее» спорт-патриотик фестивале** сизелерлек урын алды. Фестивальне оештыручы – Иҗтимагый палата комиссиясе әгъзасы, Татарстан Республикасының «Универсаль сугыш» спорт федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының региональ бүлеге президенты А.Н. Софронов. «Вакыт безне сайлады» ветераннарга һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга ярдәм фонды белән партнерлыкта бер ел эчендә биш турнир уздырылды.

Фестиваль хәрби хәрәкәтләр ветераннары истәлегенә багышланды, спортны һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга, яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә, тәҗрибә алмашу һәм спорт осталыгын камилләштерү өчен мәйданчык булдыруга юнәлдерелде.

ТР Иҗтимагый палатасының һәм «Ак Барс Созидание» хәйрия фондының уртак **проекты «Мәрхәмәтлелек маршрутлары» V яшь экскурсоводлар конкурсы** яшь буынны патриотик агартуга юнәлдерелде. Маршрутларның тематикасы туган төбәктә Бөек Ватан сугышы тарихы белән бәйле шәхесләр һәм объектлар булды. Азнакай, Арча, Баулы, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Минзәлә, Чистай, Питрәч районнарыннан, шулай ук Казан һәм Чаллы шәһәрләреннән яшүсмерләр җиңүчеләр һәм призерлар булды. Йомгаклар Халыкара хәйриячелек көнендә – 5 сентябрьдә ТР Иҗтимагый палатасында ясалды.

ТР Милли музее белән берлектә Татарстан Халыклар дуслыгы йортында Татарстаннан чыккан Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары – МХОдә һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар турында **«Геройлар һәм батырлыклар турында»**, шулай ук Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Геройлар һәм сугышлар турында» **күргәзмәләр оештырылды**.

Бауман урамында республикада туган, Бөек Ватан сугышында катнашкан 42 герой, алар арасында Советлар Союзы Геройлары, Дан, Кызыл Йолдыз һәм Кызыл Байрак орденнары кавалерлары бар, тарихы турында «Күпмилләтле Татарстан геройлары» баннер күргәзмәсе ачылды. 20 ноябрьдән күргәзмә Чаллы шәһәренә күчте.

Хәрби чорда иҗтимагый тормышны хокукый җайга салу мәсьәләләре Татарстан Республикасы Конституция советы белән уртак **«Җиңү законнары»** чарасында каралды, ул югары уку йортларының юридик факультетлары студентларын, курсантларны, кадетларны, дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләрен берләштерде.



Иҗтимагый палатада Т.Р. Кадыйров, И.А. Александровская һәм Н.М. Сабитова составында катнашкан **Татарстан халыклары Ассамблеясы патриотик эш форматларының күптөрлелеген күрсәтте**. Ел дәвамында «Ветеранга кунакка» акцияләре, буыннар очрашулары, спектакльләр, әдәби кичәләр, концертлар һәм тарихи-мәдәни чаралар уздырылды. ТР Рус милли-мәдәни берләшмәсе «Безнең геройлар» бөтенроссия иҗат марафонын уздырды. 10 концерт көне дәвамында Татарстанның 40 муниципаль берәмлегеннән, шулай ук Самара һәм Чуваш республикаларыннан 479 номер тәкъдим ителде, катнашучыларның гомуми саны 1,5 меңнән артып китте.

Иҗтимагый палатаның Мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары комиссиясе әгъзасы Д.А. Туманов җитәкчелегендә **Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Созвездие-Йолдызлык» ачык эстрада сәнгате фестивале** 55 меңнән артык катнашучыны җыйды. Фестиваль кысаларында «Йолдызлык балалары – Геройларга» акциясе эшли башлады, аның кысаларында һәр катнашучы МХО сугышчыларына теләктәшлек күрсәтеп хат язды, барлык хатлар адресатларга җибәрелде.

Республика ата-аналар советы Бөгелмә һәм Әлки районнарында **«Хәтерлибез, горурланабыз, бергә эшлибез!»** балалар һәм ата-аналар өмәсен уздырды. Бөгелмәдә «1920 елның язында кулаклар, ак гвардиячеләр терроры корбаннарының туганнар каберлеге» мемориаль җирләү һәм Советлар Союзы Геройлары стелласы территориясе төзекләндерелде. Моннан тыш, «Яшүсмер» берләшмәсенең яшүсмерләр клубларында 235 чара үткәрелде, анда якынча 4 мең яшь кеше катнашты. **«Җиңүнең 80 еллыгы» Казан волонтерлар штабы** төзелде, ул гаилә тарихларын, хәрби фоторәсемнәрне, сугышта катнашучыларның хатларын берләштерде.



Иҗтимагый палата тарафыннан «МХО зонасында иҗтимагый һәм дини оешмалар гуманитар хезмәттәшлектә» темасына киңәйтелгән утырыш уздырылды, аның йомгаклары буенча Татарстан шефлыгындагы **Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре китапханәләре өчен китаплар җыю** игълан ителде. Акциянең нәтиҗәсендә 6500дән артык китап бүләк ителде, алар арасында классик әдәбият, балалар өчен китаплар, җыелма әсәрләр бар.

«Яңа очыш канатлары» проекты кысаларында ГТО комплексын гамәлгә ашыру буенча 30дан артык чара уздырылды (386 кеше төрле дәрәҗәдәге ГТО тамгалары алды), Донбасстан 3 меңгә якын бала төрле спорт төрләре буенча **спорт сменаларында** катнашты.

Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләреннән 3200дән артык бала **балалар табибы – хирург**, Иҗтимагый палата әгъзасы К.Р. Булатов тарафыннан урында кабул ителде. Палата әгъзасы Р.Р. Гатинның **«Кыр кухнясы»** проекты кысаларында 6 кешедән торган команда көн саен 5 000 порция ризык әзерләде.



ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның заманча сәнгать галереясында узган Иҗтимагый палата комиссияләренең уртак утырышы **МХО вакыйгаларын иҗади яктан күрсәтү** мәсьәләсенә багышланды. Төп тема республика иҗат берлекләренең МХОгә багышланган сәнгать әсәрләрен иҗат итүдәге тәҗрибәсе булды. «Юл картасы» эшләнде, аңа материаллар җыю өчен хәрби хәрәкәтләр зоналарына чыгулар кертелде. Соңрак «МХО волонтерлары» фотокүргәзмәсе ачылды. Татарстан Республикасы Милли музее филиалы базасында «Татарстан – Лисичанск – Рубежное: сыкраудан торгызуга» күргәзмәсе үткәрелде.

ТР Иҗтимагый палатасының **«Игелекле экскурсияләр»** проекты МХОдә катнашучыларның гаиләләренә һәм яралы сугышчыларга ярдәм итү рәвешләренең берсе булды, ул ТР Ватан хәрбиләре гаиләләре комитеты белән берлектә «Буревестник» транспорт компаниясе һәм «Интеграция» инвалидлар региональ иҗтимагый оешмасы ярдәмендә гамәлгә ашырылды. «Буревестник» уңайлы автобуслар, ә «Интеграция» – 8 утыргычка һәм 3 инвалид креслосына исәпләнгән электр белән күтәрелә торган һәм пандусы булган автобус бирде. 2024 елдан Казан госпиталендә дәваланучы 250 яралы сугышчы Казан буенча экскурсияләрдә катнашты.

Махсус хәрби операция шартларында Россиянең **күпмилләтле халкы ягыннан армиягә ярдәм** аеруча зур әһәмияткә ия булды. Милли-мәдәни берләшмәләр ярдәме белән (Азәрбайҗан, Чечня ТР милли-мәдәни автономияләре, «Доанкет» ТР Вьетнам җәмгыяте, «Демос» ТР греклар автономиясе һәм башкалар) гуманитар йөк җыелды һәм Курск өлкәсенең фронт яны зонасына тапшырылды. Йөкне алып барып тапшыруда Иҗтимагый палата рәисе урынбасары, Дуслык йорты директоры Т.Р. Кадыйров катнашты. ТР Таҗиклар милли-мәдәни автономиясе активистлары Запорожье юнәлешендәге

сугышчыларга «Штурмовик» баллистика костюмы, беренче чират кирәк-ярак товарлары, шулай ук «Тимер» батальонына УАЗ PATRIOT автомобиле җибәрде. ТР Үзбәкләр милли-мәдәни автономиясе Курск юнәлешендәге «Төньяк» группировкасының десант-штурм бүлекчәләренең хәрби хезмәткәрләренә ВАЗ 2121 автомобиле тапшырды. «Лезгияр» лезгиннар, «Дагестан» Дагестан халыклары берләшмәсе, Ассамблея һәм Дуслык йорты хезмәткәрләре көче белән берлектә DJI Mavic 3 Pro квадрокоптерлары һәм аларга интеллектуаль очыш батареялары сатып алынды.

Ел дәвамында **«Ярдәм янәшә. Помощь рядом»** хәрәкәте тарафыннан МХО сугышчыларына һәм аларның гаиләләренә, шефлыктагы Лисичанск, Рубежное шәһәрләренә һәм фронт яны территорияләренә ярдәм күрсәтелде. Ел дәвамында 40тан артык бүлекчәгә гуманитар ярдәм тапшырылды, 16 эре партия җибәрелде.




Иҗтимагый палата әгъзасы Е.Г. Кабыш җитәкләгән Әфганстан һәм махсус хәрби операцияләр ветераннары Россия берлеге әгъзалары МХО зонасына сизелерлек ярдәм (20 дән артык конвой) күрсәтте, мондый эшкә башка иҗтимагый оешмалар да җәлеп ителде. Әлеге **эшчәнлек республикада массакүләм күренешкә әйләнде**.

Татарстан Республикасында 29 муниципаль берәмлектә 36 «Игелек.Үзәк» эшли. «Игелек.Үзәк» – ул иҗтимагый үсеш һәм волонтер, хәйрия һәм граждан башлангычларына ярдәм итү үзәге.

Татарстан Республикасында Добро.рф платформасында 237 615 волонтер һәм 5 729 ихтыярыйлык эшчәнлеген оештыручы теркәлгән.

Җиңүнең 80 еллыгы һәм Ватанны саклаучылар елы сизелерлек иҗтимагый теләктәшлеккә, волонтерлык хәрәкәтен ныгытуга ярдәм итте. Граждан җәмгыяте институтлары, милли-мәдәни берләшмәләр, яшьләр, спорт, иҗади һәм башка оешмалар көн тәртибендәге актуаль мәсьәләләргә югары дәрәҗәдә тартылуларын күрсәтте. Системалы эш, форматларның төрлелеге һәм барлык яшь төркемнәрен җәлеп итү заман сынаулары алдында **ватанпәрвәрлек, әхлаклылык һәм гаделлек кыйммәтләрен бердәм җәмгыять нигезе буларак ныгытырга** мөмкинлек бирде.

Геополитик киеренкелек арту һәм дәүләтара диалогның традицион форматларын яңадан карау чорында халыкара мөнәсәбәтләр системасын трансформацияләү шартларында дәүләтнеке булмаган коммуникация каналларының роле үсә. **Җәмгыятьтәге дипломатия тәҗрибәсе цивилизацияара диалогны хуплауның, халыклар арасында ышанычны ныгытуның нәтиҗәле коралына әверелә.**

Моңа илләрнең хокук, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренә хөрмәт һәм көнкүреш үзенчәлекләре нормалары нигезендә күмәк иминлек һәм үзара ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыру принципларын яклау буенча Россия Федерациясенең эзлекле позициясе ярдәм итә. Әлеге позиция күп кенә илләр тарафыннан хуплана һәм аңа теләктәшлек белдерелә, бу, беренче чиратта, БРИКС+ линиясе буенча хезмәттәшлекне киңәйтүдә чагыла.

Татарстан Республикасы, гармонияле милләтара һәм динара бәйләнешләрнең уникаль тәҗрибәсенә ия буларак, җәмгыятьтәге дипломатия тәҗрибәсе бурычларын гамәлгә ашыру өчен тарихи яктан төп Россия мәйданчыкларының берсе булып тора. Республиканың граждан җәмгыяте институтлары, ТР Иҗтимагый палатасын да кертеп, эре халыкара форумнарны оештыруда һәм уздыруда системалы рәвештә катнаша, анда гуманитар бурычларны хәл итүгә, традицион кыйммәтләрне саклауга һәм хезмәттәшлекне үстерүгә уртак алымнар эшләнә.

2025 елда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы «Россия – ислам дөньясы: KazanForum 2025» XVI Халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында кайбер чараларның оештыручысы һәм өстәмә оештыручысы булды, алар үз эченә динара диалогны, халык дипломатиясен һәм киләчәк икътисадында гаиләнең ролен алды:

– **«БРИКС илләре һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмалары дини оешмаларының традицион кыйммәтләрне саклауда һәм ныгытуда үзара хезмәттәшлеге мөмкинлеген үстерү»** түгәрәк өстәле, чара Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы белән берлектә үткәрелде, түгәрәк өстәлдә дини һәм иҗтимагый эшлеклеләр, шулай ук Россиядән һәм дөньяның башка илләреннән галимнәр катнашты;

– **«Мәдәни-гуманитар һәм халык дипломатиясенең 100 еллыгы: коммерциягә карамаган оешмаларның, БРИКСның иң яхшы тәҗрибәләре һәм цивилизацияара диалогның киләчәккә үсеш перспективалары»** сессиясе, чара Россия хезмәттәшлек агентлыгы белән берлектә үткәрелде һәм Россиядә җәмгыятьтәге дипломатия тәҗрибәсенең 100 еллыгына багышланды;

– **«Хатын-кыз карашы» трегы кысаларында «Киләчәк икътисадын формалаштыруда гаилә институты роле»** сессиясе, чара Россия хатын-кызлар берлеге эгидасы астында үткәрелде.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы инициативасы белән «Kazan Digital Week» Халыкара форумы көн тәртибенә коммерциягә карамаган секторны цифрлы трансформацияләү мәсьәләләре кертелде. **«Ясалма интеллект һәм коммерциягә карамаган оешмалар: социаль үзгәрешләр өчен технологияләр»** түгәрәк өстәле үткәрелде.

Җәмгыятьтәге дипломатия тәҗрибәсенең әлеге форматлары белән кызыксынуның тотрыклы үсеше билгеләнә. Аларда коммерциягә карамаган оешмаларның, фәнни җәмәгатьчелекнең һәм бизнес бергәлегенең вәкилләре Россия Федерациясеннән генә түгел, ә башка илләрдән дә катнашуы барлык илләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алган гадел дөньяви тәртип төзүдә кыйммәтләрнең уртаклыгын ассызыклый.



# 6. Сынаулар һәм үсеш мөмкинлекләре

Бүген **Татарстан социаль-икътисадый үсешнең югары дәрәҗәсен һәм граждан җәмгыяте институтларының җитлеккәнлеген күрсәтә**. Моңа дәлил булып икътисадый үсешнең мөһим күрсәткечләре буенча лидерлык позицияләре һәм масштаблы социаль программалар, гражданнарның сайлау кампанияләре барышында югары активлыгы һәм үсеш курсына ярдәм итү дәрәҗәсе тора.

Моны җәмәгать сораштырулары да раслый. «Җәмәгать фикере – Татарстан» фонды мәгълүматлары буенча 2025 ел ахырына Татарстан Республикасы халкының кимендә дүрттән өче (76,4%) Татарстан Республикасы Рәисенә ышаныч белдерә, сораштырылганнарның 82,6% ы аның эшчәнлегенә уңай бәя бирә. Муниципаль районнар башлыклары эшенең уңай бәяләнүе (һичшиксез, күбесенчә яхшы) 68% тәшкил итә. Гомумән алганда, Татарстан Республикасында 75,5% канәгать һәм бигрәк тә эшләр торышыннан канәгать. Сораштыруда катнашканнарның 72% ка якыны милләтара мөнәсәбәтләрне тыныч, тотрыклы, 82,9% ы дини өлкәдәге вазгыятьне шулай ук бәяли. Сораштырылган гражданнарның 42% ка якыны теге яисә бу дәрәҗәдә ихтыярыйлык, волонтерлык эшчәнлегендә катнашуларын раслады.

Тышкы сынауларга карамастан, сораштырулар хакимият эшчәнлегенең югары дәрәҗәдә бәяләнүен, социаль мөнәсәбәтләрне уңай күзаллауны, республика тормышына гражданлык теләктәшлеген күрсәтә.

Бу шактый ныклык запасы, ләкин тынычлану өчен сәбәп түгел. Өстәвенә, тышкы яктан куркыныч янау шартларында җәмгыятьнең берләшүе, күпчелек гражданнарның билгеле бер тискәре тенденцияләрне аңлавы һәм аның белән килешергә әзерлеге бәяләүгә җитди йогынты ясый.

Әмма МХО тәмамлангач һәм анда катнашучылар кайткач, **күп кенә мәсьәләләрне тиз арада хәл итүгә ихтыяҗ дәүләт һәм җәмгыять мөмкинлекләренә караганда күбрәк булачагын көтәргә кирәк**.

Шуңа күрә бүген, республиканың икътисадый өлкәдәге позицияләрен ныгыту белән берлектә **барлык граждан җәмгыяте институтларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү** аеруча мөһим. Бу бигрәк тә кире элемтә каналларыннан һәркемнең файдалана алуына, җәмгыятьтәге вакыйгаларга һәм ихтыяҗларга оператив һәм нәтиҗәле хәл итү мөмкинлегенә кагыла.

Яңа составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан граждан җәмгыяте институтларының булуы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге өлешендә эшләр торышына анализ ясалды, аларның күбесе бу докладта ничек булса да чагылдырылды. **Җитешсезлекләр һәм үсеш нокталары** билгеләнде, алга таба эшчәнлек өчен өстенлекләрне күзаллау бар.

Сүз дә юк, 2024 елдан бирле **социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар форумнары үткәрелмәве** төп җитешсезлек булып тора. Элек ул дәүләтнең һәм җәмгыятьнең хезмәттәшлеге мәсьәләләрен хәл итүгә коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү, граждан җәмгыяте институтларын үстерү буенча мөһим башлангычлар эшләү өчен иң уңышлы мәйданчык булган.

Шулай ук муниципаль берәмлекләр каршындагы **Иҗтимагый советларның Координация советы** эшчәнлеген торгызырга кирәк, бу исә гражданнар җәмгыяте үсешенә кешеләр өчен иң якын булган муниципаль дәрәҗәдә нәтиҗәле йогынты ясарга, мәгълүмати-методик эшне һәм иң яхшы тәҗрибәләр белән алмашуны җайга салырга мөмкинлек бирәчәк.

Шулай ук муниципаль дәрәҗәдә **социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү программаларының саны шактый кимегәне** – сроклары чыкканга 22гә кадәр калуы ачыкланды, ә яңалары кабул ителми. Вазгыятьне, әлбәттә, яхшыртырга һәм программаларга коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итүнең нәтиҗәле чараларын кертергә кирәк. ТР Икътисад министрлыгының коммерциягә карамаган оешмалар буенча рейтингы кайбер районнарда бу мәсьәләләргә йомшак дәрәҗәдә игътибар бирелүен күрсәтә. Иҗтимагый палатаның Муниципаль берәмлекләр Советы белән берлектә үткәрелгән утырышында быелның көзендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү һәм граждан җәмгыяте институтларын үстерү мәсьәләсен карау күздә тотыла.

Шунысы мөһим, республикада җирле үзидарәнең ике дәрәҗәле системасы сакланды, чөнки бер яктан, бу гавами хакимият дәрәҗәсе, икенче яктан, граждан җәмгыяте институты. Гражданнарның активлыгы, аларның үз эшчәнлекләрен оештыруы – җирле үзидарәнең нигезе.

Гражданнар җирле дәрәҗәдә карарлар кабул итү процессына никадәр күбрәк җәлеп ителгән булса, алар локаль бергәлектә диалог сыйфаты белән шулкадәр күбрәк канәгать, аларның гавами хакимият белән хезмәттәшлеге шулкадәр продуктив һәм конструктив була.

Кызганычка каршы, элек күрелгән омтылышларга карамастан, республикада һаман да «Актив гражданин» тибындагы **кире элемтәнең цифрлы платформасы эшләнмәгән**. Бүген граждан активлыгының шактый өлеше формаль булмаган килеш кала, җаваплар челтәр бергәлекләрендә эзләнә, республиканың иҗтимагый тормышына эшлекле катнашу күзәтелми.

Шул ук вакытта, тулаем алганда, граждан җәмгыятенең киләчәктәге үсеш перспективалары цифрлы инструментлардан файдалануны киңәйтүдә, шул исәптән җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда да күренә.

Иҗтимагый палата фикеренчә, республикада **коммерциягә карамаган оешмаларның социаль әһәмиятле проектларын уңышлы гамәлгә ашыруны яктырту мәсьәләләренә** җитәрлек игътибар бирелми, бу исә аларны тиражлауга һәм җәмгыять тарафыннан кабул итүгә йогынты ясый. Республика өчен әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар хисаплары ачыклыкның мисалы булырга мөмкин.

Бүгенге көндәге сынауларны исәпкә алып, **социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү республика ярдәмче программасын актуальләштерү**, шул исәптән ресурс үзәкләре эшчәнлеген камилләштерү мөмкинлеген карау максатка ярашлы булыр иде.

Республика ресурс үзәген (8 Март урамы, 18Б йорт) реновацияләүне исәпкә алып, анда берничә коммерциягә карамаган оешма урнаштыру буенча конкурслардан республиканың бердәм грант операторы көче белән **оешмаларның күпләгән саны белән эшләү мөмкинлеге**, укыту, консультацияләр һәм тренинглар оештыру өчен шартлар тудыруга күчү күздә тотыла.

Граждан активистларын закон чыгару эшчәнлегенә җәлеп итү, әгәр **Иҗтимагый палатада** карала торган мөһим закон проектлары **«беренчел укылышлар»** узса, нәтиҗәлерәк булыр иде.

ТР Иҗтимагый палатасы үз эшчәнлегендә **яшьләрдә актив тормыш позициясен кызыксындыруга** үзләренең гражданлык ролен аңлау аша аерым игътибар бирүне планлаштыра.

Билгеләнгән сорауларның күпчелеге 2026 елга расланган планда чагылыш тапты. Өстенлекләр арасында – 2026 елга иҗтимагый әһәмияткә ия чараларны һәм бурычларны гамәлгә ашыруда гражданнарның, коммерциягә карамаган оешмаларның ТР дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлектә көчләрен берләштерү. Алар түбәндәге чараларда чагыла:

– Россия Федерациясендә расланган Россия халыклары бердәмлеге елы;

– Татарстан Республикасында расланган Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы;

– IX чакырылыш РФ Дәүләт Думасына сайлаулар;

– Россия Федерациясе үсешенең һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең илкүләм максатларына ирешү;

– МХОда катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү;

– иҗтимагый башлангычларга һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм чараларын камилләштерү.

Граждан җәмгыяте институтларының иҗтимагый үзгәрешләр драйверы буларак аерым урын алып торуыннан чыгып, агымдагы елның өченче кварталында Татарстан Республикасы Гражданнар форумын үткәрү күздә тотыла.

Бүген граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында доклад шулардан гыйбарәт.

# Йомгаклау

Бүген, коммерциягә карамаган сектор, җәмгыять институтлары дәүләт белән бертигез дәрәҗәдә социаль бердәмлек һәм тотрыклылык тәэмин итә, гражданнарның төрле төркемнәре мәнфәгатьләрен чагылдыру һәм алга җибәрү өчен платформа сыйфатында чыгыш ясый.

Граждан җәмгыятенең алга баруы өчен эшнең яңа форматларын һәм нәтиҗәле карарлар эзләү белән берлектә иң яхшы тәҗрибәләрне саклау һәм үстерү, социаль әһәмияткә ия башлангычларга һәм проектларга системалы ярдәм итү чараларын арттыру, төбәкара элемтәләрне һәм халык дипломатиясен ныгыту мөһим.

Җәмгыятьтәге ихтыяҗларны тиз арада хәл итү, бәхәсләрне уңай юнәлешкә күчерү, хакимият белән диалогта конструктив чишелешләр табу мәсьәләләре актуаль булып кала.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, ТР Иҗтимагый палатасы үз миссиясен үтәү, ягъни системалы үзгәрешләр һәм һәркем өчен гадел карарлар нигезендә туган республикабызның тотрыклы үсешенә ирешү өчен хакимият белән эшчәнлектә җәмгыятьне берләштерү эшен дәвам итәчәк..